Педсовет утырышында кабул ителде
беркетмә №1, 29.08.2022ел
Боерык №34,31.08.2022ел

Камалиева Нурия Нурисламовна

Подписан: Камалиева Нурия Нурисламовна
DN: C=RU, OU=Заведующий, O=" МБДОУ ""Детский сад 321""", CN=Камалиева Нурия Нурисламовна, E=Ds321.kzn@tatar.ru
Основание: я подтверждаю этот документ
Местоположение: место подписания
Дата: 2022-09-16 17:21:47
Foxit Reader Версия: 9.7.2

РАСЛЫЙМ:
МБМБУ "321 нче балалар бакчасы" мөдире
_______________Камалиева Н.Н

**Казан шәһәре Киров районының**
**муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе**
**"Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 321 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы"ның татар теле тәрбиячесе**
**Захарова Раушания Низаметдиновнаның**
**2022 – 2023 нче уку елына эш программасы.**

**2022 год**

**Эчтәлек**


| | |
|---|---|
| 1. | Титул бите. |
| 1.1. | Циклограмма. ( Эш көне бүленеше). |
| 1.2. | «Туган телдә сөйләшәбез”. (2-3яшь). |
| 1.3. | Методик кулланманың аңлатма язуы, авторлары һәм кайда, кайчан нәшер ителүе турында мәгълүмат. |
| 1.4. | “Туган телдә сөйләшәбез” укыту методик комплекты буенча беренче номерлы кечкенәләр тө**р**кеме (2-3яшьлек ) өчен тематик план. |
| 1.5. | «Туган телдә сөйләшәбез”. Өченче номерлы уртанчылар төркеме (3-4яшьлек) балалар өчен. |
| 1.6. | Методик кулланманың аңлатма язуы, авторлары һәм кайда, кайчан нәшер ителүе турында мәгълүмат. |
| 2. | “Туган телдә сөйләшәбез” укыту методик комплекты буенча өченче номерлы уртанчылар төркемендә туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлеше буенча белем бирүэшчәнлеген оештыру төрләре. Танып белү өлкәсе. |
| 2.1. | “Туган телдә сөйләшәбез”.Уртанчылар төркеме. Комплекслы тематик план агымдагы уку елы өчен. |
| 2.2. | 4 нче һәм 6 нчы зурлар төркемнәре өчен “Туган телдә сөйләшәбез” укыту –методик комплекты. Аңлатма язуы. |
| 2.3. | “Туган телдә сөйләшәбез” укыту методик комплекты буенча 4 нче һәм 6 нчы зурлар төркемнәре өчен агымдагы уку елына комплекслы – тематик план. |
| 2.4. | “Туган телдә сөйләшәбез” укыту методик комплекты буенча икенче һәм бишенче номерлы мәктәпкә әзерлек төркемнәре өчен . Аңлатма язуы. |
| 2.5. | “Туган телдә сөйләшәбез” укыту методик комплекты буенча икенче һәм бишенче номерлы мәктәпкә әзерлек төркемнәре өчен агымдагы уку елына комплекслы – тематик план |
| 2.6. | Кулланылган әдәбият. |

# “Туган телдә сөйләшәбез” укыту методик комплекты. Өченче номерлы уртанчылар төркеме (3-4яшьлек) балалар өчен.

## Аңлатма язуы

Әлеге кулланма – татар балаларын туган телгә өйрәтү, аларның сөйләмен үстерү буенча төзелгән «Туган телдә сөйләшәбез» дип аталган методик комплектның икенче өлеше. Өйрәтү-методик комплект методик кулланманы, аудиоязмалар җыентыгын, күрсәтмә материалларны үз эченә ала. Бу комплект 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү Стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган тел өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максатыннан төзелә. Комплектның төп максаты - балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү булса, төп үзенчәлеге – тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.Сез кулга алган кулланма балалар бакчасында икенче кече яшьтәге балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә методик кулланма буларак тәкъдим ителә. Туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек конспектлары Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә чыккан «Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы» нигезендә төзелгән. Методик кулланмада федераль дәүләт таләпләре буенча өч белем бирү өлкәсе: танып белү, коммуникация (сөйләм үстерү), матур әдәбият белән таныштыру карала. Белем бирү өлкәләрен үзләштерү гомумкабул ителгән педагогик принципларга нигезләнә. Эшчәнлек конспектлары үстерешле белем бирү, белем бирү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, гуманлылык, күрсәтмәлелек һ.б. төп педагогик принципларга таянып эшләнде. Гуманлылык принцибын исәпкә алып, белем бирү процессы бала шәхесен ихтирам итүгә һәм психологик якланганлык хисләре булдыруга юнәлдерелә. Принципларның тагын берсе – үстерешле белем бирү принцибы, ягъни белем бирү нәтиҗәсендә белемнәр үзләштерелеп, күнекмәләр генә формалаштырылып калмый, ә тоемлау, аңга алу, хәтер, игътибар, сөйләм, фикерләү белән бәйләнешле барлык танып белү процесслары да, шулай ук ихтыяр һәм эмоцияләр дә үстерелә - бала шәхесенең төрле яклы үсеше алып барыла. Ахыргы елларда үстерешле белем бирү мәсьәләләре балаларның төрле төр эшчәнлеген интеграцияләү белән тыгыз бәйләнештә карала. Бу бигрәк тә оештырылган төп эшчәнлек

төрләренең танып белү, коммуникация (сөйләм үстерү) белем бирү өлкәләренә хас. Белем бирүне «якындагы үсеш зонасына» ориентлаштырып алып барганда гына ул үстерешле нәтиҗә бирә (Л.С. Выготский). Бу очракта, кагыйдә буларак, бала белемнәрне өлкәннәрнең аз гына ярдәме нигезендә үзләштерә. Тәрбияче «якындагы үсеш зонасының» баланың яше белән генә түгел, ә шәхси үзенчәлекләре белән дә бәйле булуын истә тотарга тиеш. Белем бирү барышында баланың фикерләвенә зур игътибар бирү сорала. Эшчәнлек төрләрендә сөйләмдә сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш, аваз культурасы тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру бурычлары хәл ителә.Балалар белән эшләү процессында сүзлек өстендә эш зур урын ала. Сүзлек өстендә эш - бәйләнешле сөйләм нигезе. Эшчәнлек конспектлары сүзлек өстендә эшнең өч бурычын чишә:

1. Иң беренче чиратта, гомуми кулланылыштагы лексика хисабына (предметларны, аларның төп билгеләрен, сыйфатларын, эш-хәрәкәтләрен атау) сүзлекне баету.
2. Сүзлеккә төгәллек кертү. Балаларга сүзне әйтү үрнәген бирү, аны һәр бала белән күп тапкыр кабатлау.
3. Сүзлекне активлаштыру.

Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыруның төп шарты – тәрбияченең, өлкәннәрнең грамоталы сөйләме һәм сөйләмнең морфологик, синтаксика ягын, сүз ясалу ысулларын үзләштерү буенча үткәрелә торган күнегүләр. Аваз культурасы тәрбияләү буенча эш аның сөйләм сулышын, ишетеп аңга алу, артикуляция аппаратын үстерү һ. б. шундый компонентларны үз эченә ала.

Бәйләнешле сөйләм үстерү сөйләмнең ике формасын – диалогик һәм монологик сөйләмен үстерүне күздә тота. Диалогик сөйләм үстерүдә сорау-җавап формасы, балаларның үзләренең сорау бирә, бер-берсенә мөрәҗәгать итә белүе – иң отышлы формалар. Балаларның кечкенә хикәяләрне мөстәкыйль төзи белүе монологик сөйләм барлыкка килүдә мөһим күрсәткеч булып тора.

Балаларны матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру – сөйләм үсешенең әһәмиятле чарасы. Матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру процессында без түбәндәге бурычларны чишәргә тырыштык:

1. Дөньяны бербөтен итеп кабул итү, беренчел күзаллаулар формалаштыру.
2. Әдәби сөйләм үстерү.
3. Сөйләм сәнгатенә якынайту, шул исәптән эстетик зәвык, әдәби әсәрне аңга алуларын үстерү.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишкәндә, белем бирүнең төрле алымнары, чаралары кулланыла. Дүртенче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Шундый формаларның берсе булып бармак уеннары тора. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект

үсешенә уңай йогынты ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л.С. Выготский, И.П. Павлов, А.Р. Лурия, А.А. Леонтьев һ.б.)
6 7
хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын раслыйлар. Балалар белән эшләү дәверендә төрле предметлар тотып биюләр, уеннар киң кулланыла. Балаларның игътибарын туплау, эшчәнлеккә карата кызыксыну уяту, ял иттерү (релаксация) максаты белән шигъри әсәрләргә зур игътибар бирелә. Бу әсәрләрне

укыганда, балалар, эчтәлегенә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар. Матур әдәбият, халык иҗаты, күрсәтмәлелек, предметлар белән уен хәрәкәтләре, кошларның, җәнлекләрнең образларын имитацияләү - болар барысы да нәниләрне туган телгә өйрәтүдә,
аларның сөйләмен үстерүдә зур әһәмияткә ия. Балалар белән үткәрелә торган эшчәнлек конспектлары тулы күләмле итеп язылды. Белем һәм тәрбия бирү процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда, тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә. Җәя эчендә бирелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтә. Кабатлауның төрле вариантлары бар: тәрбияче артыннан, балалар артыннан, тәрбияче белән бергә, күмәк, индивидуаль. Эшчәнлек төрләрен оештыру федераль дәүләт таләпләрендә каралган интегратив сыйфатлар
формалаштыруга: физик яктан үсеш алган, төп культура-гигиена күнекмәләрен үзләштергән; кызыксынучан, актив; интеллектуаль һәм шәхси бурычларны чишә, кеше хәленә керә белүчән, эмоциональ; өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу ысулларын, чараларын үзләштергән; үзе, гаиләсе, әйләнә-тирәсе, дәүләт, дөнья, табигать турында беренчел күзаллауларга ия булган; элементар гомумкабул ителгән нормаларны, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштергән; беренчел кыйммәткә ия булган күзаллаулар нигезендә үзенең тәртибе белән идарә итүгә һәм үз гамәлләрен планлаштыруга сәләтле; өйрәтү эшчәнлегенең универсаль нигезләрен үзләштергән бала шәхесе тәрбияләүгә юнәлдерелә.
Икенче кече яшьтәге балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик принципка нигезләнә. План ел дәверендә «Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы!», «Көз», «Мин һәм минем гаиләм», «Минем йортым, минем шәһәрем», «Яңа ел бәйрәме», «Кыш», «Ватанны саклаучылар көне», «Сигезенче март», «Халык җәүһәрләре», «Яз», «Җәй» кебек темалар үзләштерүне күздә тота. Елга ике тапкыр диагностик методикалар ярдәмендә мониторинг үткәрелә. Мониторинг нәтиҗәләре балаларның персональ карточкаларына языла.

Без, авторлар коллективы, өйрәтү-методик комплектта тәкъдим ителгән материаллар балаларга туган телне өйрәтүдә һәм аларның сөйләмен үстерүдә тәрбиячеләргә ныклы ярдәмлек булыр дип ышанып калабыз. Әлеге методик кулланма милли балалар бакчасында эшләүче педагогларга, тәрбиячеләргә, әти-әниләргә, педагогик уку-укыту йортларында белем алучы студентларга адреслана. Алардан киңәшләр, тәкъдимнәр көтеп калабыз.



УДК 373.3/4:811.512.145*00
ББК 74.102:81.2 Тат
Т81

Авторлар:Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Ж.

Рецензентлар:

Гаффарова Сәбилә Муллануровна,
Казан педагогика көллиятенең директор урынбасары;
Кадырова Рузалия Әхәтовна,
Казан шәһәренең 415нче балалар бакчасы мөдире;
Закирова Кафия Вәлиевна,
Казан шәһәренең 415нче балалар бакчасы методисты

Туган телдә сөйләшәбез. Методик кулланма / Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Ж. – Казан: Фолиант, 2013.- 224 б.

Методик кулланмада икенче кече яшьтәгеләр төркеменә йөрүче балаларның сөйләмен үстерү һәм аларны ана теленә өйрәтүнең методик нигезләре һәм хәзерге технологияләре бирелгән. Кулланмада өч-дүрт яшьлек балаларның сөйләм үсеше һәм федераль дәүләт таләпләреннән чыгып, аларның сөйләмен үстерүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне оештыру үзенчәлекләре ачыклана. Эшчәнлек оештыру конспектлары Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә басылган «Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы» нигезендә төзелгән. Әлеге кулланма танып белү, коммуникация, матур әдәбият уку белем бирү өлкәләрен үз эченә ала. Балаларның белем бирү өлкәләре эчтәлеген ни дәрәҗәдә үзләштерүләрен ачыклау максатыннан диагностик методикалар бирелә. Методик кулланма мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе хезмәткәрләренә, урта, югары һөнәри белем алучы студентларга, мәктәпкәчә белем бирү сферасында эшләгән мөгаллимнәргә, әти-әниләргә тәкъдим ителә.ISBN 978-5-905576-20-1 © Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г.,Хәбибулина И.Ж., 2013
© Фолиант, оригинал-макет, 2013

# Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлеше буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру төрләре

## ТАНЫП БЕЛҮ ӨЛКӘСЕ

Вакыты Бүлекләр Тема Бурычлар
20.08.-
10.09.
Сау
бул, җәй!
Исәнме,
балалар
бакчасы!
Кояш, чык! 1) җәй турында күзаллауларга
нигез салу, тәүлек өлешләрен
дөрес әйтергә күнектерү;
2) балаларның сөйләмен,
игътибарын, ишетү хәтерен;
күз алдына китерә, хыяллана
белүләрен; вак моториканы,
рәсем ясау күнекмәсен, иҗади
сәләтләрен үстерү;
3) балаларда табигать белән
кызыксыну тәрбияләү.
Йомшаккай
әзерләгән
сюрприз
1) агачтан ясалган уенчык-
ларны карау барышында агач
материалы, аның үзлекләре
(каты, нык) белән таныштыру;
тәрбияче сорауларына җавап
бирергә өйрәтү;

2) предметларның төсен, формасын, зурлыгын билгели белергә өйрәтү, анализаторлар эшчәнлеген, сүзлек байлыгын, хәтерләрен, игътибарларын үстерү;
3) уенчыкларга карата сак- чыл караш, уеннан соң уенчыкларны урынына кую гадәте тәрбияләү.
Манара 1) балаларны төрле зур- лыктагы һәм төрле төстәге төзү материалы - шакмаклар белән таныштыру, үрнәк буенча манара корылмасы төзергә өйрәтү.
2) предметның төсен, фор-

масын, зурлыгын атый бе- лүләренә ирешү;
3) бергә шөгыльләнү теләге уяту; балалар бакчасына карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.
11.09.-
30.09.
Көз Куян
үстергән
кишер һәм
помидор
1) балаларга табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында мәгълүмат бирү, яшелчәләр (кишер, помидор)

турындагы белемнәрен ны-
гыту;
2) балаларның яшелчәләрне
(кишер, помидор) тышкы
күренеше, тәме, формасы
буенча аера белүләренә
ирешү; игътибарын, аңга
алуларын, диалогик сөйләмен,
сенсорик күнекмәләрен
үстерү;
3) балаларда сорауларга җавап
бирү теләге уяту; табигатькә
уңай караш тәрбияләү.
10 11
1) балаларның табигатьтәге
көзге үзгәрешләр, көзге уңыш
турындагы күзаллауларын
киңәйтү, яшелчәләр (кыяр,
шалкан) турындагы белемнә-
рен ныгыту;

2) яшелчәләрне (кыяр, шал-
кан) тышкы күренеше, тәме,
формасы буенча аера белергә
өйрәтүне дәвам итү; игътибар,
аңга алу, диалогик сөйләм,
сенсорик сәләтләрен үстерү;
3) сорауларга җавап бирү
теләге тудыру; табигать белән
кызыксыну тәрбияләү.
Сары, кызыл
яфраклар
1) балаларны көз, кыш ел
фасылларының характерлы

билгеләре белән таныштыру;
бер ел вакыты икенчесен
алмаштыруы турында мәгълү-
мат бирү; көзге яфраклар
турындагы белемнәрен (яф-
ракларның төсләре үзгәрә,
алар коелалар) киңәйтү.
Авазлар әйтелешен ныгыту;
2) балаларның игътибарын,
аңга алуларын, хәтерен,
бәйләнешле сөйләмен
үстерү; көзге табигатьнең
матурлыгын күрә белергә
өйрәтү;
3) балаларда чиста, пөхтә
эшләү теләге тәрбияләү.
01.10.-
15.10.
Мин
һәм
минем
гаиләм
Кунак

каршы-
лыйбыз
1) савыт-сабаның аерым
предметлары, аларның ку-
лланылышы турында беле-
мнәренә төгәллек кертү;
тәрбияче белән бергә кыска
хикәя төзергә өйрәнүне дәвам
итү; әңгәмәгә тарту;
2) балаларның игътибарын,

аңга алуларын үстерү;
тәрбияче биргән сорауны
ишетү, аңлау һәм аңлаешлы
итеп җавап бирүләренә ирешү;
үз исемен дөрес итеп әйтә
белергә өйрәтү;
3) балаларда сөйләм этикетына
нигез салу (исәнләшү, танышу,
саубуллашу); өлкәннәргә
бу
лышу теләге уяту; савыт-
сабага сакчыл караш
тәрбияләү.
16.10.-
04.11.
Минем
йортым,
минем
шәһәрем
Мин –
«КамАЗ»
оныгы.

1) балаларны туган шәһәр,
аның исеме (Яр Чаллы),
шәһәрдә ясала торган

«КамАЗ» машинасы белән
таныштыру, юл йөрү
кагыйдәләре турында
элементар белемнәр бирү;
2) аңга алуларын, диалогик
сөйләмнәрен үстерү; сүз-
ләрне, кыска фразаларны

ачык әйтә белүләренә ирешү;
«КамАЗ» машиналары белән
кызыксынуларын үстерү;
3) туган шәһәр, «КамАЗ»
эшчеләре, аларның хезмәте
бе лән горурлану хисе
тәрбияләү.
12 13
15.11.-
31.12.
Яңа
ел бәйрәме
Тылсымлы
шкатулка.
.
1) балаларны Яңа ел бәйрәменә әзерлеккә тарту, чыршы уен чыкларының төрләре белән таныштыру, аларны күзәтергә теләк тәрбияләү;2) балаларны чыршы уен чыкларының төсен, формасын, зурлыгын, кулланылышын билгеләргә өйрәтү, диалогик сөйләмнәрен үстерү, со-рауларга җөмлә белән җавап бирергә өйрәтү; аңга алуларын үстерү; берничә сенсорик билгеләре буенча бертөрле предметларны төркемгә бе рләштерергә өйрәтә башлау;3) чыршы уенчыкларына сак караш тәрбияләү; балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру.
Куян белән
тиенне
чыршы
бәйрәменә
чакырабыз
1) балаларның кышкы та-бигатьнең характерлы үзен-чәлекләре, кыргый җәнлекләр турындагы күзаллауларын ки
ңәйтү, тикшеренүләр бары-шында суның үзлекләре турында мәгълүмат бирү; авазларның артикуляциясен ныгыту;2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, танып белү активлыкларын фор
ма

лаш-тыру;3) балаларда Яңа ел бәйрәме
уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру; җәнлекләргә карата кайгыртучанлык хисе тәрбияләү.
01.01.-
31.01.

Кыш «Чанада
шуабыз»
рәсемен
карау
1) балаларны рәсемне карарга, аның эчтәлеген аңларга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү;
2) диалогик сөйләмнәрен; күзәтүчәнлекләрен, күрсәтмә-образлы фикерләүләрен үстерү;
3) кышның матурлыгын күрә белергә өйрәтү.
Җимлек
янында.
.
1) кышлаучы кошларны кү зәтүне оештыру; аларны тышкы кыяфәтләре буенча танырга өйрәтүне дәвам итү; пумаланың очы белән ярма бөртекләре ясауны ныгыту;
2) аваз иярткемнәрен әйтүдә күнектерү; сүзлек запасын баету, күзәтүчәнлекләрен, игътибарлылыкларын үстерү;
3) кошларга карата сак караш, алар турында кайгыртучанлык, кышын аларны тукландыру теләге

тәрбияләү.

01.02.-
23.02..
Ватанны
саклаучылар
көне
Ватанны
саклаучылар
көне
1) балаларны Ватанны
саклаучылар көне белән
таныштыру;
2) балаларның игътибарын,
аңга алуларын; диалогик,
монологик сөйләмнәрен үс-
терү;
3) балаларда Туган илгә
мәхәббәт, малайларда көчле,
кыю булырга омтылыш тәр-
бияләү.
14 15
24.02.-
08.03..
Сигезенче
Март
Минем
әнием
1) әниләр турында әңгәмәдә катнашырга, әниләрнең исемен дөрес әйтә белергә өйрәтү; әзер формалардан бизәк төзеп, кәгазь битендә ябыштырырга өйрәтүне дәвам итү; 2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, сүзлек байлыгын үстерү;3) балаларда пөхтәлек, әни-ләргә карата җылы мөнәсәбәт, хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләү.
09.03.-
31.03.
Халык
җәүһәрләре
Тере һәм

уенчык

кошларны
карау
1) тере һәм уенчык кошны чагыштырып, уенчык кош – дымка уенчыгы белән таныштыру, уенчык кошның нинди материалдан ясалган булуын ачыклау; төсләрне, дымка бизәге элементларын ныгыту;2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, сорауларга тулы җавап бирергә өйрәнүне дәвам итү;3) кошлар белән кызыксыну, аларга карата сак караш, кайгыртучанлык тәрбияләү.
01.04.-
20.04.
Яз Урамда яз 1) балаларны язгы күренешләр белән таныштыруны дәвам итү (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела), язгы табигатьтәге гади бәйләнешләрне (кояш ныграк җылыта – көннәр җылына – кар эри һ.б.) ачыклау бары-шында сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру;2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, күзаллавын үс терү; 3) язгы күренешләр белән кызыксынуларын үс те рү, табигатьтә барган үзгә-решләрне күрергә өйрәтү, шатлык хисләре уяту.
02.05.-
31.05.
Җәй «Кәҗә һәм
кәҗә
бәтиләре»
рәсемен
карау
1) балаларны тәрбияче яр-
дәме белән рәсемнең эч-
тәлеген аңларга, аның ту-
рында сөйләргә өйрәтү,
йорт хайваннары турындагы
белемнәрен киңәйтү;
2) балаларның аңга алуларын,
игътибарын, диалогик сөй-
ләмен, дуслык турында кү-
заллауларын үстерү;
3) тәрбияче сөйләгәнне тыңлый
белергә өйрәтү; хайваннарга
карата кайгыртучанлык тәр-

бияләү.
Тузганак
чәчәген
карау

1) балаларны туган як
үсемлекләре (тузганак) белән
таныштыруны дәвам итү;
2) үсемлекне карау
барышында әңгәмәгә тарту;
хәтерне, игътибарны,
күзәтүчәнлекне үстерү;
3) үсемлекләр белән кызык-
сыну, эстетик хисләр тәрбияләү

**“Туган телдә сөйләшәбез”**
**3 нче уртанчылар төркеме.**
**Комплекслы тематик план**
**агымдагы  уку елы өчен.**

“Говорим на родном языке”.
Комплексно - тематический план на текущий год
для  средней группы.

**Комплекслы тематик план .**

**Уртанчылар төркеме -**

| Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|
| **1. Без балалар бакчасында** | Танышу<br>Без балалар бакчасында | 1<br>1 |
| | Әкиятләр иленә сәяхәт. | 1 |
| **2. Мин - дөньяның бер кешесе** | Әти, әни һәм мин<br>“Гаилә” рәсемен карау.<br>Г. Тукай “Безнең гаилә”шигырен уку.<br>Г. Тукай “Безнең гаилә”шигырен ятлау.<br>Гаилә<br>Мин һәм кешеләр | 1<br>1<br>1<br>1<br>2<br>2 |
| | “Көз һәм балалар” җыры.<br>Анимацион сюжет “Шалкан әкияте буенча”<br>Әйдәгез, дуслашыйк. | 2<br>1<br>1 |
| **3. Ю** | Б.Рәхмәт “Су” шигырен уку.<br>Б.Рәхмәт “Су” шигырен ятлау | 1<br>1 |
| | Качышлы уйныйбыз. | 1 |
| **4. Көз** | Көз килде<br>“Көз”рәсемен карау | 1<br>1 |
| | Качышлы уйныйбыз. | 1 |
| **5. Куян күчтәнәчләре** | Куян күчтәнәчләре | 2 |
| | “Шалкан” әкияте. | 1 |
| **6. Көз күчтәнәчләре** | Җимешләр.<br>Р.Батулла “Аю Әппәс” әкиятен сөйләү | 1<br>1 |
| | Әйдәгез, уйныйбыз. | 1 |
| **7. Табын янында.** | Ашамлыклар<br>Әбине сыйла<br>Сыйла | 2<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Без кибеткә барабыз, ашамлыклар алабыз<br><br>Аш бүлмәсе | 1<br>1<br>1 |
| | Безнең кунаклар<br>Дустыңны сыйла<br>Кунак сыйлау. | 1<br>1<br>1 |
| **8. Татар халык ашлары.** | Татар халык ашлары. | 2 |
| | Азат кунак чакыра | 1 |
| | | |
| **9. Безнең уенчыклар** | Безнең уенчыклар<br>Әйдәгез уйныйбыз<br>Уенчыклар белән уйныйбыз<br>Уенчыклар кибете<br>Без уйнарга яратабыз<br>Уйныйбыз<br>Минем яраткан уенчыкларым | 3<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | Уенчыклар<br>Паркка сәяхәт<br>Алсуның туган көне<br>Яңа ел килә<br>**Ә.Бариның “Кыш”шигырен уку** | 2<br>1<br>1<br>1 |
| **10. Кыш** | Җәнлекләр кышка әзерләнә<br>Җәнлекләр кышкы урманда<br>А.Алиш”Куян кызы”<br>Кыргый хайваннар<br>Хәйдәрнең “Керпе туны”әкиятен уку<br>Ә.Бариның “Кыш”шигырен уку. | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | Паркка сәяхәт<br>Уйныйбыз<br>Мияуга бүләк | 1<br>1<br>1 |
| **11. Халык җәүһәрләре** | Киемнәр | 2 |
| | “Ни өчен киемнәр югалган” | 1 |
| **12. Ватанны саклаучылар.** | Безнең Армия<br>Хәрби һөнәрләр<br>Очучылар<br>Без солдатлар<br>К. Булатованың “Солдатлар” шигырен уку.<br>Иң яхшы эти. | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| | | 1 |
| | Уенчыклар үпкәләгән.<br>“Күңелле уеннар”<br>Уенчыклар юабыз. | 1<br>1<br>1 |
| **13. 8 март** | Әнием турында сөйлим<br>З.Туфайлованың “Әни сүзе” шигырен ятлау. | 1<br>1 |
| | Саннар | 2 |
| **14. Яз** | Кар Бабай язны эзли<br>Яз бүләкләре<br>Нур Гайсинның“Яз килә”шигырен уку<br>“Без язны яратабыз” | 1<br>1<br>1<br>1 |
| | Уйныйбыз да, саныйбыз да | 1 |
| **15. Күчмә кошлар** | Күчмә кошлар<br>Х.Вахитның “Уңган сыерчык”шигырен уку.<br>Б. Рәхмәтнең “Яз ”шигырен ятлау. | 2<br>1 |
| | Бергәләп өйрәник<br>“Акбай һәм Мияу маҗаралары” | 1<br>1 |
| **16. Халык җәүһәрләре** | Савыт- саба<br>Кунак чакырабыз.<br>Бергәләп уйныйбыз.<br>“Күңелле ял итәбез” | 2<br>2<br>1<br>1 |
| **17. Апрель җитсә, исемеңне җырына куша тургай** | Габдулла Тукай<br>Габдулла Тукайның “Кызыклы шәкерт”шигырен уку.<br>Габдулла Тукайның “Гали белән кәҗә” шигырен ятлау. | 2<br>1<br>1 |
| | Без татарча сөйләшәбез | 2 |
| **18. Йорт хайваннары** | Йорт хайваннары<br>К.Ушинскийның “Хайваннар бәхәсе”әсәрен | 1<br>1 |
| | Бу өйдә кем яши? | 1 |
| **19. Минем дусларым** | “Торна белән Төлке” әкиятен уку.<br>“Без татарча сөйләшәбез”<br>Җ.Тәрҗемановның ”Кикрикүк”шигырен уку<br>А.Алишның”Чукмар белән Тукмар” әкияте буенча әңгәмә | 2<br>1<br>1 |
| | Без театр уйныйбыз<br>Уйныйбыз | 1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| **20. Сабантуй бәйрәме** | Сабантуйга әзерләнәбез<br>Күңелле Сабантуй | 1 |
| | Сабантуй бәйрәме | 1 |
| | | **108 сәгать** |

# 4 нче һәм 6 нчы зурлар төркемнәре өчен “Туган телдә сөйләшәбез” укыту –методик комплекты

## Аңлатма язуы.

**“Туган телдә сөйләшәбез” укыту –методик комплекты** Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (23.11. 2009)655 нче номерлы боерык нигезендә расланган “Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына федераль дәүләт таләпләре” (алга таба ФДТ.-авт.),Татарстан республикасының 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтүне ,сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру юнәлешен тормышка ашыру максатын күздә тотып төзелде.Ул түбәндәге бурычларны билгели:

- Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;
- Тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;
- бәйләнешле сөйләм үстерү;
- Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау(тоемлау) сәләте булдыру

ФДТ дә билгеләнгән 4 төп тәрбия юнәлеше үсешенә нигезләнеп,

(1-“Физик үсеш,” 2 “Социаль-шәхси үсеш”, 3-“Танып белү-сөйләм үсеше,”

4- “Нәфис-нәфасәти үсеш”) комплексы – тематик план төзелде. Ул зурлар төркемендә 40 проектны, мәктәпкә әзерлек төркемендә 32 проектны һәм шул проектлар буенча төзелгән 97 шәр эшчәнлек конспектларын үз эченә ала.

“Минем бакчам”, “Мин яратам сине Татарстан”, “Саулык –зур байлык,” “Исемең матур кемнәр куйган, ” “Кунак булсаң- тыйнак бул” “Исәнме мәктәп, ” “Кояш системасы,” “Дуслык белән көчле без, “Идел буе мозаикасы” һәм башка күп проектлар балалар тормышын чагылдыручы, үсемлек һәм тереклек дөньясына кагылышлы, экологик культура, табигатькә аңлы караш, туган җиргә, телгә мәхәббәт тәрбияләүгә булышлык итүче шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр; нәниләрдә кешелеклелек хисләре, үз-үзеңне тоту күнекмәләре, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләүгә, нәрсә – яхшы, нәрсә – начар, үзара дустанә мөнәсәбәтләргә, тормыш куркынычсызлыгы нигезләренә, юл хәвефсезлеге кагыйдәләренә, табигатьтә үз-үзеңне тоту күнекмәләренә кагылышлы эшчәнлекне үз эченә алган. Һәр эшчәнлектә халкыбызның тормыш сынавы аша узган тәрбия җәүһәрләре – мәкаль-әйтемнәр, сынамышлар, табышмаклар, эндәшләр алынды. Ана телебезнең матурлыгы, камиллеге һәм байлыгы гәүдәләнгән әлеге энҗе-мәрҗәннәр балаларның сөйләмен баетуда, тапкырлык-зирәклекләрен тирәнәйтүдә, иҗади фикерләү сәләтләрен үстерүдә ярдәмлек булыр дип ышанып калабыз.

Бу укыту-методик комплектында ФДТ күрсәткән өч белем бирү өлкәсе карала:

**-“Танып белү ” белем биру** өлкәсе табигать, аның үзенчәлекләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыру; балаларның ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү, системалаштыру; нәниләрдә экология бурычларын гамәлгә ашыруны, туган як, өлкәннәр хезмәте турында балаларның белемнәрен тирәнәйтүне максат итеп куя. Шушы максатларны тормышка ашыруга ярдәм итүче зурлар төркемендә 30 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек төркемендә 35 эшчәнлек каралган. Балалар белән эшчәнлек сәяхәт, күзәтү, тәҗрибәләр уздыру, төрле уеннар формасында уздырыла.

**- “Аралашу” белем бирү** өлкәсе нәниләрдә туган телгә мәхәббәт, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну, авазларны дөрес әйтү, бәйләнешле сөйләм культурасы булдыруга, сабыйларга кара- каршы сөйләшә белү (диалогик сөйләм) күнекмәләрен камилләштерү,сәнгатьле сөйләм чараларын үзләштерүгә булышлык итү бурычларын гамәлгә ашыра. Бу белем бирү өлкәсенә туры килгән, зурлар төркемендә 36 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек тәркемендә 38 эшчәнлек тәкъдим ителә. Авазларны кабатлау, калын һәм нечкә авазларның дифференцациясе һәр эшчәнлеккә өлеш итеп кертелде.Бу өлкәдәге эшчәнлек әңгәмә, сәхнәләштерү, өстәл театры карау, рәсемнәр, картиналар карау, алар буенча хикәя төзү, уен-викториналар; тасвирлау, үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү, хикәяне дәвам итеп сөйләү кебек эш формаларын күздә тота.

**- “Матур әдәбият”белем бирү** өлкәсе кешеләрне һәрчак яхшыга гына өндәүче, акыллы, тапкыр булырга киңәш бирүче, авыр вакытта югалып калмаска, нык ихтыярлы, батыр йөрәкле булырга өйрәтүче, яшь үзенчәлекләрен искә алып сайланган шигырьләр, хикәяләр, әкиятләрбелән танышуны, балаларны әдәби телдә сөйләшергә өйрәтүне максат итеп куя.

Бу белем бирү өлкәсе зурлар төркемендә 31 эшчәнлекне, мәктәпкә әзерлек төркемендә 30 эшчәнлекне үз эченә ала. Эшчәнлек матур әдәбият әсәрләрен уку, эчтәлеген сөйләү, ятлау кебек эш формалары кулланып оештырыла..

Укыту- методик комплекты ФДТ дә күрсәтелгән 10 белем бирү өлкәсе: (“Сәламәтлек”, “Физик культура”, Социальләштерү”, “Хезмәт”, “Куркынычсызлык”, “Танып – белү”, “Аралашу”, “Матур әдәбият уку”, “Иҗат”, “Музыка”) буенча куелган бурычларны күздә тотып эшләнде. Һәм алар турыдан-туры бердәм белем бирү эшчәнлеге стуктурасында интегральләштереп бирелде.

Укыту-методик комплектында тупланган материал балалар бакчасы педагогларына балаларның сөйләмен үстерү,тирә - юнь, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында гына түгел рәсем ясау, әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү, эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура эшчәнлекләрендә, иртән балаларны кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә кулланылыр һәм нығытылыр дип өметләнәбез.

“Туган телдә сөйләшәбез” - балаларыбызга халкыбызның тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә, туган телебезгә мәхәббәт, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт- итәгать тәрбияләргә, үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклаык, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итәр дип ышанасы килә.

Шушы җирдән, шушы туфрактан без.

Китә калсак үзгә бер якка,

Өянкеләр җырлап, таллар елап,

Сандугачлар моңы озата. – дип шагыйрә К.Булатованың шигырен

укыганда, балаларга туган җир, туган туфрак, туган телнең изгелеген, өянкеләрнең кайчан җырлаганын, талларның ничек итеп итеп елаганын, сандугачларның моңы ничек итеп күңелне кузгатканын аңлата алсак без үз максатыбызга ирешкән булырбыз.

**Тәрбиячегә ярдәмлек йөзеннән сөйләм үстерү методикасы бирелә.**

М**атур әдәбият әсәрләрен уку методикасы:**

1Әдәби әсәрне сәнгатьле итеп уку.

2Әдәби әсәрне максат куеп уку.

3Әдәби әсәр эчтәлеге буенча әңгәмә уздыру.

4 Әдәби әсәрне кабатлап уку.

**Матур әдәбият әсәрләренең эчтәлеген сөйләү методикасы:**

1Әдәби әсәрне сәнгатьле итеп уку.

2 Аңлашылмаган сүзләрне аңлату.

3Әдәби әсәрне максат куеп уку.

4 Эчтәлеге буенча әңгәмә уздыру.

5Әдәби әсәрне кабатлап уку.

6 Балалар тарафыннан әсәрнең эчтәлеген сөйләү.(5-6 бала)

**Шигырь ятлау методикасы.**

1Шигырьне сәнгатьле итеп уку.

2Шигырьне максат куеп уку.

3Шигырь эчтәлеге буенча әңгәмә

4 Шигырьне кабатлап ук

46 Балалар тарафыннан әсәрнең эчтәлеген сөйләү.(5-6 бала)

**Тасвирлау хикәяләре төзү планы:**

1Бу нәрсә?

2 Нинди өлешләрдән тора?

3Нәрсәдән ясалган? (нинди материал)

4Ни өчен кирәк?

**Рәсем буенча хикәя төзеп сөйләү .**

( Мурашковска И.Н. методикасы **)**

**1 адым-**"бүл" (Рәсемдә кем нәрсә күрә, һәрбер бала аерым –аерым әйтә, тәрбияче схематик рәвештә балалар күргән һәм әйткән рәсемнәрне түгәрәккә алып тактага ясый)

**2 адым** – "әйдә" (Балаларга эчтәлеге белән туры килгән ике рәсемне кушарга тәкъдим ителә һәм ни өчен дигән сорауга тулы җөмлә белән җавап бирүләре сорала)

**3 адым** – "нинди тавышлар ишетәсең" ( Уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү)

**4 адым** – "нинди исләр тоясың" (  Уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү)

**5адым –"р**әсемдәге әйберләрнең сыйфатларын әйтү". (Уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү)

**6 адым –** Хикәя төзү**. (**Биш адымны берләштерү)

# “Туган телдә сөйләшәбез” укыту методик комплекты буенча
# 4 нче һәм 6 нчы зурлар төркемнәре өчен агымдагы уку елына
# комплекслы – тематик план.

## Комплексłы тематик план

## Зурлар төркеме – “Туган телдә сөйләшәбез”.

| Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|
| 1. «Яхшы сүз-җан азыгы» | Танышу<br>Ягымлы сүзләр<br>Сыйла(катнаш эшчәнлек) | 1<br>1<br>1 |
| 2. А. Алиш иҗаты | А.Алиш- балалар язучысы.<br>А.Алиш “Каз белән аккош” | 1<br>1 |
| | «Чукмар белән Тукмар» (катнаш эшчәнлек) | 1 |
| 3. Хуш киләсең, ямьле көз! | Җәйләр үтте, көзләр җитте.<br>Көзге табигать | 1<br>1 |
| | “Шалкан” (катнаш эшчәнлек) | 1 |
| 4. Көз күчтәнәчләре | Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт<br>Сыйлыйбыз | 1<br>1 |
| | “Баллы кишер” (катнаш эшчәнлек) | 1 |
| | Түтәлләрдә үсте яшелчә<br>Яшелчәләр кибете<br>Бар матур бакча | 1<br>1 |
| | “Баллы кишер” (катнаш эшчәнлек) | 1 |
| 5. Мин яратам сине, Татарстан | Мин яратам сине, Татарстан<br>Туган җирем- Татарстан | 1<br>1 |
| | “Уйный-уйный эшлибез” | 1 |
| | Гүзәл туган ягыбыз<br>Туган ил кайдан башлана? | 1<br>1 |
| | Мультфильм “Акбарс” | 1 |
| 6. Төсләр дөньясы | Төсләр<br>Төсләр дөньясы | 1<br>1 |
| | “Юл маҗаралары”. | 1 |
| 7.Кем эшләми , шул ашамый. | Яшелчә салаты<br>Яшелчәләр юабыз. | 1<br>1 |
| | “Кем эшләми, шул ашамый” | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| **8.Җиләк-җимешләр** | Җимешләр<br>Уйныйбыз да, җырлыйбыз да<br>Җиләк-җимешләр | 1<br>1<br>1 |
| **9.Минем гаиләм** | Безнең гаилә<br>Әби , бабайларны хөрмәтлик. | 1<br>1 |
| | “Аш бүлмәсе” | 1 |
| **10. Табын янында** | Савыт-саба кибетенә сәяхәт.<br>Туган көн<br>Бергәләп өйрәнәбез.<br>Курчак Алиягә булыш<br>Чәй табыны | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | “Өч аю” . | 1 |
| **11.Киемнәрдә безне бизиләр** | Кием кешене бизи<br>Кием - салым кибетенә сәяхәт | 1<br>1 |
| | “Киемнәр кибетендә” | 1 |
| **12.Салкын кыш. Кышкы уеннар.** | Салкын кыш<br>Кышкы уеннар | 1<br>2 |
| | “ Хат ташучы Кар бабай.” | 1 |
| | Без суыктан курыкмыйбыз.<br>Кыш. | 1<br>11 |
| | “Киемнәр кибетендә” | 1 |
| | Кышкы уеннар<br>Ел фасыллары | 1<br>1 |
| | “Чисталыкта - матурлык” | 1 |
| **13. Кунак булсаң-тыйнак бул** | Без ашыйбыз<br>Мин кунак яратам<br>Бергәләп өйрәнәбез | 1<br>1<br>1 |
| **14. Киемнәр** | Киенергә ярдәм ит<br>Милли киемнәр. | 1<br>1 |
| | “Киемнәр кибетендә” | 1 |
| | Киемнәр дә безне бизиләр.<br>Киемнәр дөньясы | 1<br>1 |
| | ”Ни өчен киемнәр югалган” | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| **15. Йорт җиһазлары** | Матур әдәбият белән таныштыру Өстәл театры “Өч аю”.<br>Өй җиһазлары кибете. | 1<br>1 |
| | “Маша һәм өч аю” | 1 |
| **16. Муса Җәлил безнең күңелләрдә.** | Муса Җәлил безнең күңелләрдә.<br>“Батыр лыкта-матурлык”. | 1<br>1 |
| | “Шаян уенчыклар”. | 1 |
| **17. Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа** | Без әни белән кибеткә бардык<br>Әниләр бәйрәме | 1<br>1 |
| | “Өч кыз” | 1 |
| | Әни кирәк<br>Әниемнең тәмле ашлары | 1<br>1 |
| | “Туган көн” | 1 |
| **18.Без язны яратабыз** | Яз килә.<br>Яз килә, яз! | 1<br>1 |
| | “Кем нәрсә ярата?”. | 1 |
| | Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау<br>Нәүрүз – яз бәйрәме<br>Бар, юк | 1<br>1<br>1 |
| **19. Безнең канатлы дусларыбыз** | Күчмә кошлар<br>Кошлар | 1<br>1 |
| | “Алтын ай” кибете | 1 |
| **20. Габдулла Тукай иҗаты** | Габдулла Тукай<br>Г. Тукайның “Кызыклы шәкерт” шигырен уку. | 1<br>1 |
| | Тукай әсәрләреннән төзелгән мультфильмнардан өзекләр карау. | 1 |
| | Г. Тукай “Безнең гаилә”<br>“Гаилә” рәсемен карау | 1<br>1 |
| | Г. Тукай “Бала белән күбәләк” | 1 |
| **21. Чисталыкта-матурлык** | Саулык-зур байлык<br>Шигырь уку: Ә.Ерикәй “Чисталык сөябез” | 1<br>1 |
| | “Чисталыкта-матурлык” | 1 |
| **22. Җиңү алып килде май** | Сугыш ветераннары белән очрашу | 1 |
| **23.Кунак көтәбез** | “Винни-пух кунакка бара”. | 1 |
| | “Туган көн” | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| **24. Хәрәкәттә-бәрәкәт** | Минем яраткан спорт төре.<br>Шигырь уку: В Хәйруллина “Туплар” | 1<br>1 |
| | Арыслан баласы һәм ташбака ничек җыр җырлаган” | 1 |
| **25. Чәчәкле җәй.** | Чәчәкләр – тормыш яме<br>Чәчәкле җәй. | 1<br>1 |
| | Сабантуйга әзерләнәбез | 1 |
| **26. Күңелле сабантуй** | Күңелле Сабантуй уеннары<br>Сабан туена әзерлек<br>Сабан туена әзерлек | 1<br>1<br>1 |
| | | **104** |

# “Туган телдә сөйләшәбез” укыту методик комплекты буенча икенче һәм бишенче номерлы мәктәпкә әзерлек төркемнәре өчен агымдагы уку елына комплекслы – тематик план

## Аңлатма язуы.

“Туган телдә сөйләшәбез” укыту –методик комплекты Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (23.11. 2009) 655 нче номерлы боерык нигезендә расланган “Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына федераль дәүләт таләпләре” (алга таба ФДТ.-авт.),Татарстан республикасының 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтүне, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру юнәлешен тормышка ашыру максатын күздә тотып төзелде. Ул түбәндәге бурычларны билгели:

- Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;
- Тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;
- Бәйләнешле сөйләм үстерү;
- Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау(тоемлау) сәләте булдыру

ФДТ дә билгеләнгән 4 төп тәрбия юнәлеше үсешенә нигезләнеп,
(1-“Физик үсеш”, 2- “Социаль-шәхси үсеш”, 3-“Танып белү-сөйләм үсеше”,
4- “Нәфис-нәфасәти үсеш”) комплекслы – тематик план төзелде. Ул зурлар төркемендә 39 проектны, мәктәпкә әзерлек төркемендә 31 проектны һәм шул проектлар буенча төзелгән зурлар төркемендә 98, мәктәпкә әзерлек төркемендә 100 эшчәнлек конспектын үз эченә ала.

“Минем бакчам”, “Мин яратам сине, Татарстан”, “Саулык –зур байлык” “Исеменә күрә-җисеме ”, “Кунак булсаң- тыйнак бул”, “Исәнме мәктәп”, “Кояш системасы”, “Дуслык белән көчле без” , “Китап кайдан килә” һәм башка күп проектлар балалар тормышын чагылдыручы, үсемлек һәм тереклек дөньясына кагылышлы, экологик культура, табигатькә аңлы караш, туган җиргә, телгә мәхәббәт тәрбияләүгә булышлык итүче шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр; нәниләрдә кешелеклелек хисләре, үз-үзеңне тоту күнекмәләре, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләүгә, нәрсә – яхшы, нәрсә – начар, үзара дустанә мөнәсәбәтләргә, тормыш куркынычсызлыгы нигезләренә, юл хәвефсезлеге кагыйдәләренә, табигатьтә үз-үзеңне тоту күнекмәләренә кагылышлы эшчәнлекне үз эченә алган. Һәр эшчәнлектә халкыбызның тормыш сынавы аша узган тәрбия җәүһәрләре – мәкаль-әйтемнәр, сынамышлар, табышмаклар, эндәшләр алынды. Ана телебезнең матурлыгы, камиллеге һәм байлыгы гәүдәләнгән әлеге энҗе-мәрҗәннәр балаларның сөйләмен баетуда, тапкырлык-зирәклекләрен тирәнәйтүдә, иҗади фикерләү сәләтләрен үстерүдә ярдәмлек булыр дип ышанып калабыз.

Бу укыту-методик комплектында ФДТ күрсәткән өч белем бирү өлкәсе карала:

-“Танып белү ” белем биру өлкәсе табигать, аның үзенчәлекләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыру; балаларның ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү, системалаштыру; нәниләрдә экология бурычларын гамәлгә ашыруны, туган як, өлкәннәр хезмәте турында балаларның белемнәрен тирәнәйтүне максат итеп куя. Шушы максатларны тормышка ашыруга ярдәм итүче зурлар төркемендә 28 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек төркемендә 36 эшчәнлек каралган. Балалар белән эшчәнлек сәяхәт, күзәтү, тәҗрибәләр уздыру, төрле уеннар формасында уздырыла.
- “Аралашу” белем бирү өлкәсе нәниләрдә туган телгә мәхәббәт, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну, авазларны дөрес әйтү, бәйләнешле сөйләм культурасы булдыруга, сабыйларга кара- каршы сөйләшә белү (диалогик сөйләм) күнекмәләрен камилләштерү,сәнгатьле сөйләм чараларын үзләштерүгә булышлык итү бурычларын гамәлгә ашыра. Бу белем бирү өлкәсенә туры килгән, зурлар төркемендә 39 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек тәркемендә 37 эшчәнлек тәкъдим ителә. Авазларны кабатлау, калын һәм нечкә авазларның дифференциясе һәр эшчәнлеккә өлеш итеп кертелде.Бу өлкәдәге эшчәнлек әңгәмә, үстерелешле диалог (балалар сорау бирә, сорауларга җавап кайтара), сәхнәләштерү, өстәл театры карау, рәсемнәр, картиналар карау, алар буенча хикәя төзү, уен-викториналар; тасвирлау, үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү, хикәяне дәвам итеп сөйләү кебек эш формаларын күздә тота.
- “Матур әдәбият”белем бирү өлкәсе кешеләрне һәрчак яхшыга гына өндәүче, акыллы, тапкыр булырга киңәш бирүче, авыр вакытта югалып калмаска, нык ихтыярлы, батыр йөрәкле булырга өйрәтүче, яшь үзенчәлекләрен искә алып сайланган шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр белән танышуны, балаларны әдәби телдә сөйләшергә өйрәтүне максат итеп куя. Бу белем бирү өлкәсе зурлар төркемендә 31 эшчәнлекне, мәктәпкә әзерлек төркемендә 30 эшчәнлекне үз эченә ала. Эшчәнлек матур әдәбият әсәрләрен уку, эчтәлеген сөйләү, ятлау кебек эш формалары кулланып оештырыла..
Укыту- методик комплекты ФДТ дә күрсәтелгән 10 белем бирү өлкәсе: (“Сәламәтлек”, “Физик культура”, Социальләштерү”, “Хезмәт”, “Куркынычсызлык”, “Танып – белү”, “Аралашу”, “Матур әдәбият уку”, “Иҗат”, “Музыка”) буенча куелган бурычларны күздә тотып эшләнде. Һәм алар турыдан-туры бердәм белем бирү эшчәнлеге стуктурасында интегральләштереп бирелде.

Укыту-методик комплектында тупланган материал балалар бакчасы педагогларына балаларның сөйләмен үстерү, тирә - юнь, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында гына түгел рәсем ясау, әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү, эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура эшчәнлекләрендә, иртән балаларны кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә кулланылыр һәм ныгытылыр дип өметләнәбез. “Туган телдә сөйләшәбез” - балаларыбызга халкыбызның тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә, туган телебезгә мәхәббәт, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт- итәгать тәрбияләргә, үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклылык, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итәр дип ышанасы килә.

Шушы җирдән, шушы туфрактан без.
Китә калсак үзгә бер якка,
Өянкеләр җырлап, таллар елап,
Сандугачлар моңы озата. – дип шагыйрә К. Булатованың шигырен

укыганда, балаларга  туган җир, туган туфрак, туган телнең изгелеген, өянкеләрнең кайчан җырлаганын, талларның ничек итеп итеп елаганын, сандугачларның моңы ничек итеп күңелне кузгатканын   аңлата алсак без үз максатыбызга ирешкән булырбыз.

Тәрбиячегә ярдәмлек  йөзеннән сөйләм үстерү методикасы бирелә.

Матур әдәбият әсәрләрен уку методикасы:

1). Әдәби  әсәрне сәнгатьле итеп уку.
2). Әдәби әсәрне максат куеп уку.
3). Әдәби әсәр эчтәлеге  буенча әңгәмә уздыру.
4). Әдәби әсәрне кабатлап уку.

Матур әдәбият әсәрләренең эчтәлеген сөйләү методикасы:

1). Әдәби әсәрне сәнгатьле итеп уку.
2). Аңлашылмаган сүзләрне аңлату.
3). Әдәби әсәрне максат куеп уку.
4).  Эчтәлеге буенча әңгәмә уздыру.
5). Әдәби әсәрне кабатлап уку.
6). Балалар тарафыннан әсәрнең эчтәлеген сөйләү. (5-6 бала)

Шигырь ятлау методикасы:

1). Шигырьне сәнгатьле итеп уку.
2). Шигырьне максат куеп уку.
3). Шигырь эчтәлеге буенча әңгәмә.
4).  Шигырьне кабатлап уку.
5).  Балалар тарафыннан әсәрнең эчтәлеген сөйләү. (5-6 бала.)

Тасвирлау хикәяләре төзү планы:

1). Бу нәрсә?
2).  Нинди өлешләрдән тора?
3). Нәрсәдән ясалган? (нинди материал?)
4). Ни өчен кирәк?

Рәсем буенча хикәя төзеп сөйләү:
( Мурашковска И.Н. методикасы. )

1 адым-“Бүл” (Рәсемдә кем нәрсә күрә, һәрбер бала аерым –аерым әйтә, тәрбияче схематик рәвештә балалар күргән һәм әйткән рәсемнәрне түгәрәккә алып тактага ясый.)
2 адым – “Әйдә” (Балаларга эчтәлеге белән туры килгән ике рәсемне кушарга тәкъдим ителә һәм ни өчен дигән сорауга тулы җөмлә белән җавап бирүләре сорала.)
3 адым – “Нинди тавышлар ишетәсең?” ( Уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү.)
4 адым – “Нинди исләр тоясың?” ( Уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү)
5адым –“Рәсемдәге әйберләрнең сыйфатларын әйтү”. (Уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү)
6 адым – Хикәя төзү. (Биш адымны берләштерү)

## Мәктәпкә әзерлек төркеме.

### Комплекслы тематик план
### Мәктәпкә әзерлек төркеме – “Туган телдә сөйләшәбез”. Агымдагы уку елы өчен.

| Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|
| **1. Әйдәгез, танышабыз!** | Әйдәгез, танышабыз<br>Тәмле сүз – җан азыгы | 1<br>1 |
| | “Мияу адашкан” | 1 |
| **2. Тату гаилә** | Минем өем<br>Тату гаилә | 1<br>1 |
| | “Аю баласы дөнья белән таныша” | 1 |
| **3. Абдулла Алиш иҗаты** | А. Алиш иҗаты белән танышу.<br>А.Алиш “Сертотмас үрдәк” әкияте | 1<br>1 |
| | «Батыр Мияу белән куркак Куянкай» | 1 |
| **4. Алтын көз** | Алтын көз<br>Көз җитте | 1<br>1 |
| | “Шалкан” | 1 |
| **5. Көзге байлык** | Яшелчәләр | 2 |
| | «Кем эшләми, шул ашамый.” | 1 |
| **6. Көз күчтәнәчләре** | Җиләк-җимешләр<br>Көз күчтәнәчләре | 1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| | “Без сыйланабыз” | 1 |
| **7. Икмәк – яшәү терәге** | “Игенченең тырышлыгы кырларыннан күренә”<br>Кунак чакырдык | 1<br>1 |
| | “Юмарт аю” | 1 |
| **8. Ашамлыклар** | Ашамлыклар<br>Кунак көтәбез | 1<br>1 |
| | “Кафега барабыз” | 1 |
| **9. Савыт-саба** | Савыт-саба | 2 |
| | “Тәмле” кафесы ачабыз | 1 |
| **10. Өй җиһазлары** | Минем өем, өй җиһазлары | 1 |
| | “Тәмле” кафесында | 1 |
| **11. Милли киемнәр** | Әбиемнең серле сандыгы<br>Кием кешене бизи | 1<br>1 |
| | “Күңелле уеннар” | 1 |
| **12. Минем туган җирем** | Татарстан буйлап сәяхәт<br>Спорт бәйрәменә барабыз | 1<br>1 |
| | “Көчлеләр, кыюлар, җитезләр” | 1 |
| **13. Башкалам - Казан** | Башкалам - Казан<br>“Туган илем – туган өем” | 1<br>1 |
| | Әниләр бәйрәменә барабыз | 1 |
| **14. Кыргый хайваннар** | Кыргый хайваннар | 2 |
| | “Циркта” | 1 |
| **15. Ишек алдында** | Йорт кошлары<br>Йорт хайваннары | 1<br>1 |
| | “Төлке һәм каз” мультфильмы | 1 |
| **16. Кыш килде** | Кыш килде<br>Кыш | 1<br>1 |
| | “Безнең дуслар” | 1 |
| **17. Кышкы уеннар** | Кышкы уеннар<br>Яңа ел бәйрәме | 1<br>1 |
| | “Кар малай” мультфильмы | 1 |
| **18. Кыш. Кышкы уеннар** | Кыш. Кышкы уеннар | 2 |
| | “Шаян кошлар” | 1 |
| **19. Кышлаучы кошлар** | Кышлаучы кошлар | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | Кошлар кафесы<br>Кошларга ярдәм итик! | 1<br>1 |
| | “Әйдә, бие!” | 1 |
| | “Урманда зур концерт” | 1 |
| **20. Киемнәр** | Киемнәр<br>Кышкы киемнәр | 1<br>1 |
| | “Акбай туган көнгә барырга әзерләнә” | 1 |
| **21. Муса Җәлил** | Муса Җәлил | 2 |
| | “Мияуның туган көне” | 1 |
| **22. И туган тел, и матур тел...** | Бөтендөнья телләр көне<br>И туган тел, и матур тел... | 1<br>1 |
| | “Урман китапханәсендә” | 1 |
| **23. Безнең шәһәр** | Безнең шәһәр | 2 |
| | “Уйный-уйный укыйбыз” | 1 |
| **24. Ямьле яз** | Ямьле яз | 2 |
| | «Урман мәктәбендә» | 1 |
| **25. Әкияттә кунакта** | Әкияттә кунакта<br>“Хуш киләсең, Нәүрүз!” | 1<br>1 |
| | “Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерү | 1 |
| **26. Күчмә кошлар** | Күчмә кошлар | 2 |
| | “Кем нәрсә ярата?” | 1 |
| **27. Белем иленә сәяхәт** | Белем иленә сәяхәт<br>Серле чәчәк<br>Уку бүлмәсе | 2<br>1<br>1 |
| | “Уйный-уйный укыйбыз” | 1 |
| **28. Мәктәп** | Без мәктәпкә барабыз | 2 |
| | “Без инде хәзер зурлар - мәктәпкә илтә юллар” | 1 |
| | “Юл мажаралары” | 1 |
| **29. Урман-безнең байлыгыбыз** | Урманда<br>Нәрсә ул “Кызыл китап?” | 1<br>1 |
| | Габдулла Тукай | 1 |
| **30. Габдулла Тукай** | Г. Тукай әкиятләренә сәяхәт<br>Без - Тукай оныклары | 1<br>1 |
| | Г. Тукай “Шүрәле” | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| **31. Әкияттә кунакта** | «Эш беткәч, уйнарга ярый»<br>“Алтын бөртекләр”<br>«Агачлар да авырый» | 1<br>1<br>1 |
| **32. Белем иленә сәяхәт** | Могҗизалар кыры<br>Белем иленә сәяхәт | 1<br>1 |
| **33. Без уйнарга яратабыз** | Казанга спорт бәйрәменә барабыз<br>Без уйнарга яратабыз<br>Сюжетлы-рольле уеннар | 1<br>2<br>1 |
| **34. Җиңү бәйрәме** | Алар безгә җиңү бүләк итте<br>Җиңү бәйрәме | 1<br>1 |
| **35. Хуш бакчам, исәнме мәктәп** | Кабатлау.<br>«Хуш бакчам, исәнме мәктәп» | 1<br>1 |
| | | **108 сәгать** |

**Кулланылган әдәбият:**


1. *Зарипова З.М.* Туган телдә сөйләшәбез: 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек. – Казан: ФОЛИАНТ, 2012.-304 б.
2. *Зарипова З.М.* Татарча сөйләшәбез (6-7 яшьлек балаларга татар теле өйрәтү): методик кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.-72 б.
3. *Закирова К.В*. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия. – Казан: РИЦ, 2011.-560 б.
4. *Закирова К.В*. Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе: методик кулланма. – Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.-424 б.
5. *Закирова К.В*., *Мортазина Л.Р.* Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак: балалар бакчасында уеннар: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма. – Казан: Редакционно-издательский центр, 2012.-192 б.
6. *Зарипова З.М., Исаева Р.С.* Үстерешле уеннар: методик кулланма. – Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.-128 б.
7. *Закирова К.В*., *Мортазина Л.Р.* Әй уйныйбыз, уйныйбыз ...: Балалар бакчасында хәрәкәтле уеннар: балалар бакчасы

тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма. – Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.-224 б.
8. *Гарәфиева Г.З.* Сөмбеләне кем белә?/ Балалар бакчалары тәрбиячеләре һәм музыка җитәкчеләре өчен методик ярдәмлек. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2003.-191 б.
9. *Исаева Р.С.* Методическое пособие для воспитателей (по обучению детей татарскому языку), групповых воспитателей “200 игр” II часть по проекту «Растём играя» - 34 стр.
10. *Исаева Р.С.* Методическое пособие для воспитателей (по обучению детей татарскому языку), групповых воспитателей “200 игр” III часть по проекту «Мы уже большие» - 36 стр.

**Туган телдә сөйләшик** (рус төркемендә тәрбияләнүче татар балаларына ана теле өйрәтү), 6-7 яшь: методик кулланма.
**Авторлары:** Гомәрова И.Т. 58 нче “Тирәккәй” балалар бакчасы;
Җиһангирова Н.В. 11 нче “Йолдыз” балалар бакчасы;
Гумирова Г.М. 1 нче “Шатлык” балалар бакчасы;
Заһидуллина Т.И. 42 нче “Ал чәчәк” балалар бакчасы.

**Аудиокушымта:**

1. *Закирова К.В., Кадырова Р.* Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе: методик әсбап өчен аудио-кушымта. – Компания “АКСУ”, 2013.
2. *Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ.* Туган телдә сөйләшәбез: балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү (уртанчылар төркеме): методик кулланма өчен аудио-кушымта. – Компания “АКСУ”, 2013.
3. Җырлап биеп уйныйбыз: мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен җырлы-биюле уеннар аудиоҗыентыгы.

## Балалар бакчасында татар балаларына ана теле өйрәтү программасы.

### Аңлатма язуы

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләр саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан

Республикасы дәүләт программасы»нда мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Бу - республикабызда эшләп килә торган милли балалар бакчалары өчен кадрлар әзерләү, аларның белемен күтәрү һәм методик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре. Әлеге проблемаларның бер өлеше “Туган телдә сөйләшәбез” өйрәтү-методик комплектлары ярдәмендә чишелә. Тәкъдим ителгән әсбап – татар балаларын туган телгә өйрәтү, аларның сөйләмен үстерү буенча методик кулланма. Аның төп максаты ана телендә балаларның дөрес һәм яхшы телдән сөйләмен формалаштыру. Кече яшьтән үк баланың сөйләмен үстерү аның аралашу, танып белү, әхлакый һәм рухи юнәлешләр нигезен билгели.

Ул 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү Стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган тел өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максатыннан төзелгән һәм “Туган телдә сөйләшәбез” дип аталган методик әсбап балалар бакчасында беренче кече яшьтәге балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә. “Туган телдә сөйләшәбез” дип исемләнгән методик комплект икенче кече яшьтәгеләр, уртанчылар, зурлар, мәктәпкә хәзерлек төркемнәре өчен дә әзерләнә. Бу комплектның төп максаты балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү булса, төп үзенчәлеге – тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

Туган телдә сөйләшергә өйрәтү гаиләдә башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Ул балаларга ана телендә тәрбия һәм белем бирү өчен мөмкинлекләр тудыру, халкыбызның рухи байлыгына, мәдәниятенә якынайту шартларында алып барыла. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне туган телгә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

Беренче кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасыннан аерыла. Балаларны туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү әйләнә-тирә белән таныштыру процессында бара. Шушы үзенчәлекләрне исәпкә алып, кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеге эчтәлеген төзегәндә әйләнә-тирә предметларны һәм күренешләрне танып белүдә нәрсә чыганак булып торуы игътибар үзәгенә алына. Балаларның сөйләмен үстерү “Кроха” программасында (Г.Г. Григорьева, Н.П. Кочетова, Д.В. Сергеева һ.б.) күрсәтелгән түбәндәге эшчәнлек төрләренә нигезләнеп төзелә:

I. Табигый шартларда табигать һәм социаль тирәлек белән турыдан туры таныштыру.

1. Табигатьне (күренешләрне һәм объектларны) күзәтү.
2. Предметлы дөнья белән таныштыру: предметлар һәм кораллар (исеме, сыйфаты, үзлекләре, эш-хәрәкәтләре).
3. Социаль күренешләр (үзең, якын кешеләр, өлкәннәр хезмәт турында күзаллаулар) белән таныштыру.

II. Образлы уенчыклар, пластик художестволы образлар аша тирә-юнь белән белән таныштыру

1. Уенчыклар карау.
2. “Тылсымлы капчык”, “Бу өйдә кем (нәрсә) яши?” дидактик уеннары, курчак белән дидактик уеннар.
3. Уеннар, күңел ачулар, уен-көлкеләр.
4. Йомыш кушулар (индивидуаль һәм кечерәк төркемнәргә бүлеп).

III. Художестволы картиналары аша (живописный, графический художественный образ) (буяулар һәм буяусыз

ясалган образлар (графика) әйләнә-тирә белән таныштыру.

1. Өстәлгә куела торган кечкенә картиналарны, китаптагы иллюстрацияләрне, стенадагы картиналарны карау.

2. “Җанлы” кечкенә картиналар белән эшчәнлек.

IV. Нәфис сүз аша әйләнә-тирә белән таныштыру.

1. Матур әдәбият, юаткычлар, шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр уку.

2. Тәрбияче белән бергә кыска гади әкиятләрнең эчтәлеген сөйләү.

V. Күрсәтмәлелектән башка тирә-юнь белән таныштыру һәм сөйләм үстерү.

1. Күрсәтмәлелектән башка һәм ситуциядән тыш тәрбияченең сөйләве.

2. Балалар белән әңгәмәләр һәм сөйләшүләр (тәҗрибәдән чыгып, күзәтүләрдән соң).

Методик әсбапта танып белү, коммуникация, матур әдәбият белән таныштыру кебек өч белем бирү өлкәсе карала. Нәниләр эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезендә бара. План ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күздә тота. Болар - “Балалар бакчасы”, “Көз”, “Мин дөньяның бер кешесе”, “Минем әйләнә-тирәм”, “Кыш”, “Яңа ел бәйрәме”, “Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр”, “Халык иҗаты”, “Яз”, “Җәй”. Елга ике тапкыр диагностик методикалар ярдәмендә мониторинг үткәрелә. Мониторинг нәтиҗәләре балаларның персональ карточкаларына языла.

Туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек конспектлары Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә чыккан “Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы” нигезендә төзелгән. Авторлар эшчәнлек конспектлары язганда үстерелешле өйрәтү, өйрәтү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, гуманлылык, күрсәтмәлелек һ.б. төп педагогик принципларга таяналар. Өйрәтү-тәрбия процессы балаларның “якындагы үсеш зонасында” (Л.С. Выготский) бара. Бу процессны әйдәп баручылар - тәрбиячеләр.

Өченче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Эшчәнлек төрләрендә сөйләм үсешенең *сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш, аваз культурасы тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру* бурычлары хәл ителә.

Балалар белән эшләү процессында *сүзлек эше* зур урын ала. Сүзлек эше- бәйләнешле сөйләм нигезе. Балалар бакчасында сүзлек эшенең өч бурычы чишелә:

1. Иң беренче чиратта, гомуми кулланылыштагы лексика хисабына (предметларны, аларның төп билгеләрен, сыйфатларын, алар белән эш-хәрәкәтләрен атау) сүзлекне баету.

2. Сүзлеккә төгәллек кертү. Балаларга сүзне әйтү үрнәген бирү, аны һәр бала белән күп тапкыр кабатлау.

3. Сүзлекне активлаштыру.

*Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыруның* төп шарты – тәрбияченең, өлкәннәрнең грамоталы сөйләме һәм сөйләмнең морфологик, синтаксик ягын, сүзъясалу ысулларын үзләштерү буенча үткәрелә торган күнегүләр.

*Аваз культурасы тәрбияләү* буенча эш аның сөйләм сулышы, ишетеп кабул итү, артикуляция аппаратын үстерү һ. б. шундый компонентларны үз эченә ала.

*Бәйләнешле сөйләм үстерү* сөйләмнең ике формасын - диалоглы һәм монологлы сөйләм үстерүне күздә тота. Диалоглы сөйләм үстерүдә сорау-җавап формасы, балаларның үзләренең сорау бирә, бер-берсенә мөрәҗәгать итә белүе – иң отышлы формалар. Балаларның кечкенә хикәяләрне мөстәкыйль төзи белүе монологлы сөйләм барлыкка килүдә мөһим күрсәткеч булып тора.

Балаларны *матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру* – сөйләм үсешенең әһәмиятле бурычы һәм чарасы. Матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру түбәндәге бурычларны чишкәндә тормышка ашырыла:

1. Дөньяны бербөтен итеп кабул итүне, күзаллауларны формалаштыру.

2. Әдәби сөйләмне үстерү.

3.Эстетик зәвыкны, әдәби әсәрне кабул итүне үстерү.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишкәндә өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла. Шундый чараларның берсе булып, бармак уеннары тора. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л.С. Выготский, И.П. Павлов, А.Р. Лурия, А.А. Леонтьев һ.б.) хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын исбатлыйлар.

Балалар белән эшләү дәверендә төрле предметлар тотып биюләр, уеннар киң кулланыла. Нәниләр уенчыкларны яшерәләр, эзлиләр, табалар. Мондый уеннар балаларда зур кызыксыну уята, тәрбияче күрсәткән хәрәкәтләрне балалар тырышып кабатлыйлар, "куян булып сикерәләр", "кошлар булып очалар", җим чүплиләр", "аю кебек алпан-тилпән йөриләр", "әтәч булып кычкыралар" һ.б. Бу уеннарда музыка әсәрләрен куллану балаларның фонематик ишетү сәләтен, ритмикасын, эмоциональ сферасын да баета, үстерә.

Нәниләр белән эшләгәндә "Җанлы картиналар" куллану зур урын алып тора. "Җанлы картиналар" - тышкы кыяфәтләрен көтмәгәндә үзгәртәләр һәм шуның белән балаларның игътибарын җәлеп итәләр. Алар эчтәлеге буенча ике-өч төрле эшчәнлек өчен кулланыла ала. Мондый очракта эшчәнлекнең аерым эпизодларын үзгәртергә кирәк. Мәсәлән, катнашучыларның санын кыскартырга яки арттырырга, яңа элементлар кертергә мөмкин. "Җанлы картиналар"ны темалар буенча сайлау мөһим: урам, йорт һәм кыргый хайваннар, кошлар, кибет һ.б. белән таныштыру.

Балаларның игътибарын туплау, эшчәнлеккә карата кызыксыну уяту, ял иттерү (релаксация) максаты белән шигъри әсәрләргә зур игътибар бирелә. Бу әсәрләрне укыганда балалар эчтәлегенә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар: "яфраклар, кар бөртекләре кебек очалар", "кер юалар, чайкыйлар, сыгалар", "кояшны сәламлиләр", "кояш нурлары ясыйлар" һ.б.

Матур әдәбият, халык иҗаты, күрсәтмәлелек, предметлар белән уен хәрәкәтләре, кошларның, җәнлекләрнең образларын имитацияләү - болар барысы да нәниләрне туган телгә өйрәтүдә, аларның сөйләмен үстерүдә зур әһәмияткә ия. Балалар белән үткәрелә торган эшчәнлек конспектлары тулы, күләмле итеп язылды. Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә.

Җәя эчендә күрсәтелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтә. Кабатлауның төрле вариантлары бар: тәрбияче артыннан, балалар артыннан, тәрбияче белән бергә, күмәк, индивидуаль.

Балаларны активлаштыру балаларның җавапларын конкретлаштыру, аерым сүзләрне, фразаларны, хәрәкәтләрне кабатлату максаты белән эшләнә.

Тәрбияче балаларга гомуми сораулар белән мөрәҗәгать итә, барлык балаларга да бирелгән сорауны кечкенә бала үзенә бирелгән дип кабул итми, шуңа күрә тәрбиячегә соравын конкретлаштырырга кирәк (- Балалар, алма нинди төстә? – Әмир, алма нинди төстә? – Гүзәл, алма нинди төстә? - Балалар, минем янга килегез әле. – Марат, син дә кил әле. –Алсу, син дә кил.).

Без, авторлар коллективы, өйрәтү-методик комплектта тәкъдим ителгән материаллар балаларга туган телне өйрәтүдә һәм аларның сөйләмен үстерүдә тәрбиячеләргә ныклы ярдәмлек булыр дип ышанып калабыз. Әлеге методик әсбап милли балалар бакчасында эшләүче педагогларга, тәрбиячеләргә, әти-әниләргә, педагогик уку-укыту йортларында белем алучы студентларга адреслана. Алардан киңәшләр, тәкъдимнәр көтеп калабыз.

## Өченче яшьтәге балаларның сөйләм үсеше үзенчәлекләре

Өченче яшьтәге балаларның сөйләм үсешендә мөһим үзгәрешләр бара. Танып белү сферасы камилләшә, сөйләм функцияләре арта. Сөйләм зурлар белән генә түгел, ә балаларның бер-берсе белән аралашу чарасы да булып тора.

Сөйләмне үзләштереп, бала предметларны гына түгел, ә сүзләргә, фразаларга да игътибар итә башлый. Ул зурларның инструкциясен, кушкан, катлаулырак йомышларны да ишетә, кабул итә һәм үти ала. Бу яшьтә сүзлек коммуникатив функциясе белән берлектә гомумиләштерү функциясенең дә камилләшүе дәвам итә. Балаларның сөйләмен формалаштыруда кабул итүнең әһәмияте зур. Бу яшьтә әйләнә-тирә дөньяны сенсор танып белү өстенлекле урын алып тора. Баланың күзаллаулар запасы арта һәм һәр нәрсәне бала сүзләр белән белдерә башлый. Бу үз чиратында сүзлек күләме артуга китерә. 2 яшьтә бала сүзлегендә 270-300 сүз 2,5 яшьтә 400-500 сүз булса, 3 яшьтә 1000-1500 сүзгә җитә. Балалар яңа сүзләрне генә түгел, ә сөйләм әйләнмәләрен дә бик тиз отып алалар һәм кабатлый башлыйлар.

Балалар сөйләмендә бәйлек сүзләр дә очрый, сыйфат һәм рәвешләрнең саны арта. Ел ахырына балалар үз сөйләмнәрендә сыйфат фигыльдән һәм хәл фигыльдән башка барлык сүз төркемнәрен дә кулланалар. Болар барысы да балага үз фикерен формалаштырырга һәм җөмләләрдә белдерергә булышлык итәләр. Балалар кушма җөенке җөмләләрдән дә файдаланалар. Кече яшьтәге балалар нәрсә кирәген, нәрсә күргәннәрен һәм ишеткәннәрен әйләнә-тирәдәгеләргә ачык итеп аңлата беләләр. Булган тәҗрибәләренә нигезләнеп, өлкәннәр әйткән фразадагы һәр аерым сүзне аңлый һәм хәтерендә калдыра.

Сөйләмнең коммуникатив функциясе камилләшә. Бала диалоглы сөйләмне үзләштерә башлый. Кече мәктәпкәчә яшь чорында диалоглы сөйләм сөйләмдә аралашуның төп формасы булып тора. Үз фикерләрен теләп белдерергә өйрәнә. Өченче яшь ахырына балалар күп сораулар белән мөрәҗәгать итәләр, бу аларның сөйләм һәм фикерләү үсеше турында әйтә. Ике

яшьтән соң баланың яшьтәшләре белән аралашу теләге арта. Фонетик яктан караганда әле баланың сөйләме камил түгел. Өч яшькә туган телнең барлык авазларын кабул итсә дә, аларны бик дөрес итеп әйтә алмыйлар.

Өченче яшьтәге бала аның белән аралашканда зурларның нәрсә турында сөйләвен яхшы аңлыйлар. Алар белән үткән һәм киләчәк турында да сөйләшергә була. Сөйләмнең актив булмаган формасы барлыкка килә. Балалар әдәби әсәрләрне, әкиятләрне, зурлар сөйләгәнне тыңлыйлар һәм аңлыйлар.

Кабул иткән нәрсәләрен бала үз теләге белән сөйләмдә чагылдырырга омтыла (сөйли, эчтәлеген сөйли). Тасвирый сөйләм һәм монологлы сөйләм формалаша. Болар барысы да баланың күзаллаулары киңәюе, аның мөстәкыйльлеге һәм хыял итүе үсеше белән бәйле. Бу яшь чоры сүз иҗаты үсеше өчен башлангыч булып тора. Ул баланың хисләрен, кичерешләрен ачык чагылдыра.

Баланың сөйләмендә үзенең төрле хисләрен, кичерешләрен ачык итеп чагылдыра белүе нигезендә ел ахырына сөйләм тагын сәнгатьлерәк була башлый. Болар барысы да аның шәхес үсешенә зур йогынты ясый. Сүзлек эше, сөйләмнең грамматик ягы, аваз культурасы, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру өстендә эшләү кебек бурычларны максатчан чишкәндә генә баланың сөйләм үсешендә уңышларга ирешергә мөмкин.

Беренче кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасыннан аерылып тора. Балаларны туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү әйләнә-тирә белән таныштыру барышында алып барыла. Шушы үзенчәлекләрне исәпкә алып, кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеге эчтәлеген төзегәндә әйләнә-тирә предметларны һәм күренешләрне танып белүдә нәрсә чыганак булып торуы игътибар үзәгендә торды. Балаларның сөйләмен үстерү эше “Кроха” программасында күрсәтелгән түбәндәге эшчәнлек төрләренә нигезләнеп төзелде:

1. Табигый шартларда табигать һәм социаль тирәлек белән турыдан туры таныштыру.

1). Табигатьне (күренешләрне һәм объектларны) күзәтү.

2). Предметлы дөнья белән таныштыру: предметлар һәм кораллар (исеме, сыйфаты, үзлекләре, эш-хәрәкәтләре).

3). Социаль күренешләр (үзең, якын кешеләр, олылар хезмәт турында күзаллаулар) белән таныштыру.

2. Образлы уенчыклар, пластик художество образлары аша тирә-юнь белән белән таныштыру

1). Уенчыклар карау.

2). “Тылсымлы капчык”, “Бу өйдә кем (нәрсә) яши? дидактик уеннары, курчак белән дидактик уеннар.

3). Уеннар, күңел ачулар, уен-көлкеләр.

4). Йомыш кушулар (индивидуаль һәм кечерәк төркемнәргә бүлеп).

3. Художество картиналары аша (буяу һәм буяусыз ясалган образлар (графика) әйләнә-тирә белән таныштыру.

1). Өстәлгә куела торган кечкенә картиналарны, китаптагы иллюстрацияләрне, стена картиналарын карау, “җанлы” кечкенә картиналар белән эшчәнлек.

4. Нәфис сүз аша әйләнә-тирә белән таныштыру.

5. Күрсәтмәлелектән башка тирә-юнь белән таныштыру һәм сөйләм үстерү.

## Белем бирү эшчәнлеге планнары

| Үткәрү вакыты | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| **20.08.-10.09.** | **Безнең бакча** | “Чишенү бүлмәсен карау” | Балаларны чишенү бүлмәсе, аның билгеләнеше, андагы җиһазлар белән таныштырырга, группадагы бүлмәләрдә ориентирлашу тәҗрибәсе тупларга. Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, диалогта катнашу теләген үстерергә. Җиһазларга сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | Йомшаккай бездә кунакта | Балаларның группадагы уенчыклар турындагы белемнәрен киңәйтергә, тәрбияче сорауларына җавап бирү осталыгы формалаштырырга, уенчык исемнәре һәм аларның эш-хәрәкәтен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлек запасын киңәйтергә. Тыңлау һәм сорауларга җавап бирү теләге үстерергә. Сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | Йомшаккай тагын бездә кунакта. | Балаларны уенчыкларны карарга һәм аларның аерым өлешләрен билгеләргә өйрәтергә; уенчыкларның өлешләре исемнәрен, төсен, хәрәкәтен белдерә торган сүзләрне актив сүзлеккә кертергә. Тәрбияче соравына кычкырып җавап бирү осталыгын үстерергә. Сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте, көлкеле уенчыклар белән уйнаудан канәгатьләнү, шатлану хисләре тәрбияләргә. |
| | | Е.Батуринаның “Тупны коткарабыз” картинасын карау. | Картинаның эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә; аның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтергә. Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, тәрбияче артыннан аерым сүзләрне һәм фразаларны актив кабатлауларын үстерергә. Башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләргә. |
| | | Юыну бүлмәсен карау. | Балаларның юыну бүлмәсендәге предметларның (сабын, сөлге, кран, су, теш щеткасы, теш пастасы) функциональ билгеләнеше турындагы күзаллауларын ачыкларга. Сүзләрне (сабын, сабынны, сабын белән һ.б.)төрле грамматик формаларда куллану осталыгын, сөйләм активлыгын, инициативасын үстерергә. Балаларда сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте**,** пөхтәлек, чисталык, башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләргә. |
| **11.09.-30.09.** | **Көз** | Көзге табигать. | Көз турында балаларның элементар күзаллауларын (табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр, кешеләр киеме) формалаштырырга. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, тәрбиячене тыңлый белү осталыгын үстерергә.<br>Көзге табигатькә соклану хисләре тәрбияләргә. |
| | | Җиләк-җимешләр. | Тышкы билгеләре һәм тәме буенча җиләк-җимешләр аерырга өйрәтергә; җиләк-җимешләр һәм аларның уңышын җыеп алу турында күзаллауларын киңәйтергә, җиләк-җимешләрнең исемнәре һәм аларнын билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баетырга.<br>Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, сенсор сәләтләрен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Балаларда сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте, әйләнә-тирә табигать объектларына кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | “Безнең Алсу” сериясеннән картина карау. | Картинадагы предметларны аера һәм атый, картинаның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә белергә өйрәтергә, сүзлекне активлаштырырга.<br>Балаларның игътибарын, хәтерен, тәрбияче күрсәтмәләрен ишетә һәм үти белүләрен үстерергә.<br>Картинаны кызыксынып карау теләге тәрбияләргә. |
| | | Помидор, кыяр, кишер белән таныштыру | Балаларның помидор, кыяр, кишер турындагы белемнәрен ныгытырга; помидор, кыяр, кишернең форма, төс, тәм үзенчәлекләре (кызыл, йомшак, шома, тәмле, сусыл, хуш исле помидор, помидор шар формасында; яшел, каты, шома, кытыршы кыяр; шома, кызыл, тәмле, каты кишер) белән таныштырырга.<br>Балаларның сенсор тоемлауларын, тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирә белү осталыкларын үстерергә.<br>Балаларда сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте, зурлар хезмәтенә хөрмәт, сәламәт тормыш алып бару теләге тәрбияләргә. |
| | | Картинкадагы кошларны карау. | Балаларда күгәрчен, саескан турында гомуми күзаллаулар булдырырга; аларның кызыклы гадәтләрен күрергә өйрәтергә.<br>Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сүзлек запасын үстерергә.<br>Кошларга карата йомшак караш, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләргә. |
| | | Көз (йомгаклау чарасы). | Балаларның көз турындагы белемнәрен (яфраклар саргая, сары яфраклар, яфраклар коела, яңгырлар күп ява, кешеләр җылы киемнәрен кияләр) ныгытырга. Тәрбияче сорауларына дөрес җавап бирергә, рәсем ясаганда буяуны кәгазь битенә дөрес һәм тигез төшерергә өйрәтергә. Төсләрне ныгытырга.<br>Балаларның актив сөйләмен, ишетеп кабул итүне, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерергә. Балаларда рәсем ясауга кызыксыну уятырга.<br>Көзге табигать белән соклану хисләре, пөхтәлек тәрбияләргә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **1.10.-15.10.** | **Мин дөньяның бер кешесе** | Минем исемем бар | Баланы үзенең һәм иптәшләренең исемен әйтергә өйрәтергә, иптәшләренең исемен истә калдырырга, оялчанлыкларын җиңәргә ярдәм итәргә.<br>Тәрбияче әйткәнне ишетүдә һәм аңлауда, кайбер фразаларны (Минем исемем Алсу) кабатлауда күнектерергә. Балаларның хәтерен, игътибарын үстерергә.<br>Балаларда үзләренә һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләргә. |
| | | Бу - мин. | Организм һәм аның өлешләре турында балаларда күзаллау формалаштырырга, балага үзен бербөтен итеп кабул итәргә өйрәтергә, гәүдә өлешләре турында белемнәрне ачыкларга һәм ныгытырга.<br>Гәүдә өлешләренең атамалары (баш, күзләр, колаклар, борын, авыз, тешләр, чәчләр, куллар, аяклар) хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга.<br>Үзеңне, үзеңнең гәүдә өлешләрен ярату һәм сакчыл караш тәрбияләргә, культура-гигиена күнекмәләрен үтәү теләге тудырырга. |
| **16.10.-04.11.** | **Минем әйләнә-тирәм** | Яраткан уен бүлмәбез. | Балаларны балалар бакчасы шартларына ияләндерүне дәвам иттерергә, уен (группа) бүлмәсе һәм алдагы почмаклар белән таныштырырга, һәр әйбернең үз урыны дигән күзаллауны балаларның аңына җиткерергә.<br>Сүзләрне һәм кыска фразаларны ачык әйтүләрен үстерергә, сүзлекне активлаштырырга.<br>Җиһазларга сакчыл караш һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык тәрбияләргә. |
| | | “КамАЗ” машинасы. | Балаларны “КамАЗ” машинасын һәм аның өлешләрен таный, атый белергә өйрәтергә, уенның сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр ясау осталыгы булдырырга.<br>Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, хәтерен, сөйләмен, эмоциональ сферасын үстерергә.<br>Балаларда йөк транспортына, өлкәннәр хезмәтенә кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | “Минем урамым” “җанлы картинка”сын карау. | Балаларны урам һәм аның объектлары белән таныштырырга. аларга карата кызыксыну тудырырга.<br>Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, сүзлеген үстерергә.<br>Урамга соклану хисе тәрбияләргә. |
| **15.11.-31.12.** | **Яңа ел бәйрәме** | Электр лампасы белән таныштыру. | Электр турында балаларга элементар төшенчә (электр тогы электр чыбыкларында яши; утны яндыру өчен өзгечкә (выключатель) басарга кирәк, шуннан соң электр чыбыкларыннан ток йөри башлый) бирергә. Электр, ток, чыбык, өзгеч (выключатель) сүзләре хисабына сүзлекне киңәйтергә һәм активлаштырырга.<br>Балаларның игътибарын, хәтерен, кабул итүләрен үстерергә. Ток белән бәйләнешле булган куркынычсызлык кагыйдәләрен балаларга җиткерергә.<br>Сакчыллык тәрбияләргә. |
| | | Гирлянда. | Балаларга гирлянда турында элементар белемнәр бирергә, электр тогы турындагы күзаллауларын ныгытырга, кызыл, яшел, сары төсләрне таный һәм аера белүдә күнектерергә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Балаларның игътибарын, кызыксынучанлыгын, сүзлеген һәм шатлану хисләрен үстерергә.<br>Бергә шөгыльләнү теләге тәрбияләргә. |
| | | Яшел чыршы.<br>. | Балаларны чыршыны карарга өйрәтергә, Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларына төгәллек кертергә һәм баетырга.<br>Балаларның “Яңа ел бәйрәме” темасы буенча сүзлекләрен активлаштырырга, тәрбияче соравына җавап бирү осталыкларын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор сәләтләрен үстерергә.<br>Матурлыкны күрә һәм соклана белү хисләре, чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | Чыршы бизибез.<br>. | Балаларның Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын баетуны дәвам итәргә.<br>Балаларның “Яңа ел бәйрәме” темасы буенча сүзлекләрен активлаштырырга, тәрбияче соравына җавап бирү осталыкларын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор сәләтләрен үстерергә.<br>Чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләргә |
| | | Без музыка залында. | Чыршы бәйрәменә әзерләнү уңаеннан балаларны музыка залының бизәлеше, чыршы уенчыклары белән таныштырырга (материалы, төсе, формасы); чыршы уенчыклары, йомры, пыяла, шома, ялтырый сүзләре хисабына балалар сүзлеген активлаштыруны дәвам итәргә.<br>Балаларның кабул итүләрен, күзәтүчәнлеген, игътибарын, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Балаларда эстетик хисләр тәрбияләргә. |
| **01.01.-31.01.** | **Кыш** | Ап-ак кар ява. | Балаларны кар һәм аның сыйфаты (ап-ак, эри, йомшак, салкын, җиңел) белән таныштырырга, тәрбияче сорауларына җавап бирүдә күнектерергә.<br>Балаларның сүзлек запасын, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерергә.<br>Кышкы табигатькә соклану хисе, бергәләп уйнау теләге тәрбияләргә. |
| | | Алсуны урамга киендерәбез. | Балаларның кышкы киемнәр турындагы белемнәренә төгәллек кертергә; прогулкага киендерү эзлеклелеген һәм киемнәрнең билгеләнешен истә калдырырга өйрәтергә, тәрбияче сорауларына җавап бирүдә күнектерергә.<br>Балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сүзлек запасын үстерергә.<br>Башкаларга ярдәм итү теләге, киемнәргә сак караш тәрбияләргә. |
| | | Ләйлә суыктан курыкмый. (О.И.Соловьева картинасы буенча). | Картинада ясалган предметларны дөрес танып һәм атап, картинаны карарга өйрәтергә; предметларны, эш-хәрәкәтне, төсне белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүзлекне активлаштырырга, картинаның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирүдә күнектерергә.<br>Кабул итүне, игътибарны, хәтерне үстерергә.<br>Сюжетлы картинкалар карау теләге тәрбияләргә. |
| | | Күгәрченнәр, | Табигать объектларына булган кызыксынуларын стимуллаштырырга; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | чыпчыклар – безнең нәни кошчыклар | мәйданчыкка килгән кошлар белән таныштырырга; “гөр-гөр”, “чырык-чырык”, “кар-кар” аваз ияртемнәрен ачык әйтүдә күнектерергә; томшык, сикерә, гөрлиләр, җим, чүплиләр, чырылдый, җитез, өлгер сүзләре хисабына сүзлекне баетырга. Балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә. Кошлар турында кайгырту, аларга ярдәм итү, аларны тукландыру теләге тәрбияләргә. |
| **01.02.-08.03.** | **Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр** | Безнең әтиләр. (Сюжетлы картинкалар карау). | Балаларны әтиләр һөнәренә кагылышлы булган сюжетлы кечкенә картинкаларны карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтергә; эш гамәлләрен белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга. Балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, сүзлек запасын үстерергә. Төрле профессия кешеләренә һәм әтиләр хезмәтенә карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | Безнең апа. (Тәрбияче ярдәмчесенең хезмәтен күзәтү). | Тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән бәйле эш хәрәкәтләрен таный һәм атый белергә өйрәтергә (савыт-саба юа, ашарга алып килә, сөлгеләрне алмаштыра, бүлмәне җыештыра һ.б.); сүзлекне активлаштырырга, аны яңа сүзләр белән баетырга. Уенчыкларны зурлыгы буенча классификацияләргә өйрәтергә. Балаларның игътибарын, күзәтәчәнлекне, тәрбиячене ишетә һәм сорауларга җавап бирү, катлаулы булмаган биремнәрне үти белү осталыгын үстерергә Әйләнә-тирәдәге кешеләр хезмәтенә кызыксыну һәм тыңлаучанлык тәрбияләргә. |
| | | “Алсу бәйрәмгә җыена” дидактик уены. | Якын тирәлектәге предметлар (киемнәр, аларның төсе һәм материалы) белән таныштыруны дәвам итәргә; сүзлекне активлаштырырга, ефәк, ак төстә кебек яңа сүзләр кертергә. Балаларның игътибарын, хәтерен, сорауларны ишетә һәм аларга бер сүз яки кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын үстерергә. Курчак белән уйнарга теләк һәм курчакларга сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | Безнең әниләр. (Сюжетлы картинкалар карау). | Балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы булган сюжетлы кечкенә картинкаларның эчтәлеген аңларга өйрәтергә; эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга. Балаларның кабул итүләрен. куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерергә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Төрле һөнәр кешеләренә һәм әниләр хезмәтенә карата кызыксыну, хөрмәт тәрбияләргә.. |
| **09.03.-20.03.** | **Халык иҗаты** | Матрёшкалар. | Балаларны, халык уенчыклары буларак, матрёшкалар белән таныштыруны дәвам итәргә; матрёшканы ачарга һәм дөрес итеп җыярга өйрәтергә; сүзлек запасын киңәйтергә һәм активлаштырырга; балаларны үзләренә әйтелгән (мөрәҗәгать ителгән) сүзләрне тыңлый белүдә күнектерергә; матрёшкага карата уңай эмоцияләр формалаштырырга. Игътибарны, хәтерне, сенсор сәләтләрне, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә<br><br>Халык иҗатына кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | Матрёшкалар. | Халык уенчыкларын дөрес атауда, төсендә һәм размерында булган аермалыкларны күрә белүдә күнектерергә; сүзлекне (зур, кечкенә, сарафан, яулык) активлаштырырга.<br><br>Балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br><br>Балаларда халык уенчыкларына кызыксыну тәрбияләргә. |
| **01.04.-30.04.** | **Яз** | Яз, яз килә... | Балаларга язгы күренешләр турындагы элементар белемнәр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела) бирергә. Сүзлек запасын киңәйтергә һәм активлаштырырга.<br>Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерергә.<br>Язгы күренешләргә кызыксыну, табигатьтә барган үзгәрешләргә шатлана белүләрен тәрбияләргә. |
| | | Җәнлекләр урманда яшиләр. | Җәнлекләр турында балаларның белемнәрен киңәйтергә һәм ныгытырга, җәнлекләрне таный һәм атый белергә өйрәтергә.<br>Балаларның диалоглы сөйләмен активлаштырырга, фикерләүне, мөстәкыйльлекләрен үстерергә.<br>Җәнлекләргә карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | Сыерчыклар, карлыгачлар килде (картинкалар карау). | Балаларны кошларны картинкада танырга һәм атарга өйрәтергә. Балаларның сүзлеген активлаштырырга, сүзлеккә сыерчык, сыерчык оясы, карлыгач сүзләрен кертергә.<br>Игътибарны, күзәтүчәнлекне, тәрбияче белән аралашу, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Кошларга һәм табигатнең башка объектларына кызыксыну, кошларга карата сакчыл караш, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләргә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | Песиле тал бөреләрен карау. | Балаларны песиле тал, аның өлешләре (ботаклар, бөреләр) белән таныштырырга; табигатьтәге язгы күренешләр турында белемнәр формалаштыруны дәвам итәргә; сүзлек запасын киңәйтергә һәм сүзлекне активлаштырырга (песиле тал, ботак, бөре, йомшак, хуш исле).<br>Балаларның кабул итүен, игътибарын күзәтүчәнлекләрен, хәтерен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Табигать объектына карата сак караш, кызыксыну, табигатьтәге матурлыкны күрә белүләрен тәрбияләргә. |
| **01.05.-31.05.** | **Җэй** | Тузганак чәчәген карау. | Балалрны үсемлекләр белән таныштыруны дәвам итәргә; тузганак чәчәге турында белемнәр бирергә, аны танырга, атарга, төзелеше (чәчәге, сабагы, яфраклары) буенча аера белергә өйрәтергә; сүзлек запасын киңәйтергә; тузганак, чәчәк, сабак сүзләрен сөйләмдә активлаштырырга.<br>Балаларның сенсор сәләтләрен, кабул итүләрен, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерергә.<br>Табигать белән турыдан-туры аралашудан шатлык хисләре уятырга; матурлыкны күрә белүне, үсемлекләргә сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | Йорт хайваннары. | Балаларның йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) турындагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтергә. Хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен атауда күнектерергә.<br>Сүзлекне баетырга, тәрбиячене сорауларына җавап бирү, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләге үстерергә.<br>Йорт хайваннарына кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | “Балалар тавыкны һәм чебиләрне ашаталар” (авторлары В. Езикеева, Е. Радина) картинасын карау. | Балаларны картинаны карарга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, тәрбияченең һәм иптәшләреңнең аңлатмаларын тыңларга өйрәтүне дәвам итәргә.<br>Сөйләмне томшык, тавык, чебиләр, табак кебек сүзләр хисабына баетырга, игътибарны, хәтерне, образлы фикерләүне үстерергә.<br>Йорт кошларына карата сак караш тәрбияләргә. |
| | | Ком үзлекләре. | Балаларны комны тикшерү ысулларына (комны учка алып, йомарларга һәм сибәргә), төсе буенча комның дымлылыгын билгеләргә өйрәтергә.<br>Коры, дымлы, юеш, сибелүчән, сибелә, әвәләү сүзләре хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга, игътибарны, сенсор сәләтләрне үстерергә.<br>Ком белән уйнауга кызыксыну тәрбияләргә. |

## 3. Матур әдәбият

| **Үткәрү** | **Бүлекләр** | **Тема** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| **вакыты** | | | |
| **20.08.-10.09.** | **Безнең бакча** | “Үчтеки, үчтеки” такмагын уку | Фольклор әсәрләренә кызыксыну уятырга; шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтергә.<br>Балаларның эмоциональ сферасын үстерергә.<br>Нәфис сүзгә мәхәббәт тәрбияләргә |
| | | Ә.Бикчәнтәеваның “Туп-туп-тубыбыз” шигырен уку | Балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә, таныш предметларны таный һәм атый белергә өйрәтергә, шигырьне укыганда, шигырьнең аерым сүзләрен әйтергә мөмкинлек бирергә, тупның төсләрен ныгытырга.<br>Балаларның эмоциональ сферасын үстерергә.<br>Уңай эмоциональ атмосфера тудырырга, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | С.Сөләймановaның “Ике” шигырен уку | Балаларда шигъри әсәргә кызыксыну уятырга, поэтик әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтергә, баланың үзе турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итәргә, “кул”, “аяк”, “колак”, “күз”, сүзләре хисабына сүзлекне киңәйтергә һәм активлаштырырга.<br>Һәр әгъзаның яшәү өчен әһәмияткә ия булуын һәм кирәклеген тоемлауларын үстерергә.<br>Культура-гигиеник күнекмәләр тәрбияләргә. |
| **11.09.-30.09.** | **Күз** | Хайваннарны чакыру эндәшен уку | Эндәшнең эчтәлеген аңларга өйрәтергә, фольклорның бу төр жанрына кызыксыну уятырга, текстның эчтәлеге буенча аваз ияртемнәрен, ымлыклар әйтүдә күнектерергә, тәрбияченең сорауларына аңлап җавап бирүләрен ныгытырга.<br>Балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерергә.<br>Хайваннарны ярату теләге тәрбияләргә. |
| | | Д.Гарифулинның “Йә, алар кемнәр икән” шигырен уку. | Шигъри әсәрне аңлап кабул итәргә өйрәтүне дәвам итәргә, “бак-бак”, “Мә-мә”, “Кар-кар” аваз ияртемнәрен кабатларга.<br>Балаларны шигырьдә бирелгән диалогка җәлеп итәргә; сүзлекне үстерергә һәм активлаштырырга.<br>Кошларга, хайваннарга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләргә. |
| | | Б.Рәхмәтнең “Су” шигырен уку. | Текстка туры китереп, хәрәкәтләр ясарга өйрәтергә, шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә, [ю] авазын ачык итеп әйтүдә күнектерергә, шигырьнең эчтәлегенә эмоциональ җавап бирүләренә булышлык итәргә.<br>Сүзлекне үстерергә һәм активлаштырырга.<br>Культура-гигиена күнекмәләрен тәрбияләүне дәвам итәргә |
| **1.10.-15.10.** | **Мин дөньяның бер кешесе** | Г.Тукайның “Гали белән кәҗә” шигырен уку. | Шигъри әсәрне аңларга өйрәтергә; балаларга дөньянын бер кешесе дигән күзаллауны бирергә. Кәҗәне танырга өйрәтүне дәвам итәргә.<br>Кәҗә, чирәм, сакал сүзләре хисабына сүзлек запасын киңәйтергә, хәрәкәтләрне үстерергә.<br>Бер-беренә карата һәм хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләргә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | З.Туфайлованың “Ул зу-у-у-ур үскән” шигырен уку | Шигъри әсәрне кабул итәргә һәм хезмәтнең нәтиҗәсен күрә белергә өйрәтергә, утырткан, сипкән, үскән кебек эш-хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр хисабына сүзлекне киңәйтергә, активлаштырырга; шигырьне истә калдыруларына булышлык итәргә; сүз төркемнәрен дөрес кулланып диалоглы сөйләмне баетырга.<br>Уңай эмоциональ халәтне үстерергә.<br>Гөлләргә карата сакчыл караш, гөлнең матурлыгына соклана белүләрен тәрбияләргә. |
| | | “Песи-нечкәбил” бишек җырын уку. | Шигъри әсәрнең эчтәлеген аңлатырга, бишек җырын сәхнәләштерергә һәм текстка туры китереп хәрәкәтләр башкара белергә өйрәтергә.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>Фольклор әсәрләренә кызыксыну тәрбияләргә. |
| **16.10.-04.11.** | **Минем әйләнә-тирә.** | М.Җәлилнең “Маэмай” шигырен уку. | Шигъри әсәр белән таныштырырга, аңлап кабул итәргә өйрәтергә, бармак театры элементларын куллануны дәвам итәргә.<br>Сүзлек запасын киңәйтергә (маэмай, борын, йөгерә, өрә, ишетә, күрә).<br>Йорт хайваннарына кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | М. Җәлилнең “ Әтәч” шигырен уку. | Күрсәтмәлек кулланмыйча әдәби әсәрне тыңлый һәм кабул итү күнекмәләрен формалаштырырга, кычкырганда барлыкка килгән тавышлары буенча йорт кошларын таный һәм атый белергә өйрәтергә, [к] авазының әйтелешен ныгытырга.<br>Шигырьне бармаклар театры ярдәмендә сәхнәләштерү күнекмәләрен үстерергә.<br>Йорт кошларына карата мәхәббәт тәрбияләргә. |
| | | Җ.Тәрҗемановның “Маэмай” шигырен уку | Шигъри әсәрне аңларга өйрәтүне дәвам итәргә, аерым сүзләрне (Акбаем, маэмаем, өрә) һәм зур булмаган фразаларны (“ташлар ыргытмагыз!”, “Мине котыртмагыз!”) кабатларга өндәргә.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>Эткә карата миһербанлылык тәрбияләргә. |
| **15.11.-31.12.** | **Яңа ел бәйрәме** | Ә.Бикчәнтәеваның “Беренче адым” шигырен уку. | Балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә; кайбер сүзләрне әйтергә өндәргә; бирелгән сорауларга җавап бирергә өйрәтергә. Игътибарын үстерергә.<br>Күмәк эшчәнлек күнекмәләре тәрбияләргә. |
| | | “Карга әйтә...” эндәшен уку. | Шигъри әсәрне кабул итәргә өйрәтергә, кошлар турында балаларның белемнәрен ныгытырга һәм киңәйтергә; аларның тышкы кыяфәтенә игътибар итәргә, сүзлекне баетырга; [к] авазының дөрес әйтелешен булдырырга.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>кошларга карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| **01.01.-31.01.** | **Кыш** | Ә.Ерикәйнең “Беренче кар” шигырен уку | Шигъри әсәрне аңлап кабул итәргә өйрәтергә дәвам итәргә; әсәр аша табигать дөньясына җәлеп итәргә, кышкы күренешләр турында белемнәрен формалаштырырга; “йомшак”, “ап-ак” сыйфатлары хисабына сүзлек запасын |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | киңәйтергә һәм активлаштырырга.<br>Катлаулырак сорауларга җавап бирә белүләрен, хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерергә.<br>Табигатькә мәхәббәт, туган телне өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | Ж.Тәрҗемановның “Йокы бабай” әкиятен сөйләү. | Хикәянең эчтәлеген балаларга аңларга ярдәм итәргә.<br>Игътибар белән тыңлауларын үстерергә.<br>Бирелгән сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләргә. |
| | | С. Летованың “Кар бабай” хикәясен уку. | Күләме буенча зур булмаган әдәби әсәрне (хикәяне) күрсәтмәлелектән башка гына тыңларга һәм сорауларга аңлаешлы итеп җавап бирергә өйрәтүне дәвам итәргә, балаларның әңгәмәдә җиңел һәм иркен аралашуларына ирешергә, сүзлек запасын киңәйтергә (яхшы күңел, йомшак күңел, киң күңел).<br>Балаларның игътибарын, бергәләп тыңлау күнекмәсе үстерергә.<br>Сүз сәнгатенә кызыксыну тәрбияләргә. |
| **01.02.-08.03.** | **Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр** | Ш.Маннурның “Яратам” шигырен уку. | Балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә; шигырьне тыңлау теләге уятырга, сорауларга аңлап җавап бирүдә, [ә] авазын ачык итеп әйтүдә күнектерергә.<br>Балаларның игътибарын, кабул итүен үстерергә.<br>Әти-әниләргә, туганнарга мәхәббәт тәрбияләргә. |
| | | “Кәккүк-чыпчык” уены**.** | [Ч] һәм [к] авазларын дөрес һәм ачык итеп әйтергә өйрәтергә, сүзлекне активлаштырырга.<br>Балаларның эмоциональ сферасын үстерергә.<br>Фольклор әсәрләренә кызыксыну тәрбияләүне дәвам иттерергә. |
| | | Г.Таһированың “Йокла, курчак” шигырен уку. | Балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә; шигырьне тыңлау теләген уятырга, [ә], [ү] авазларын ачык итеп әйтүдә күнектерергә.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>Курчакка карата кайгыртучанлык тәрбияләргә. |
| | | Ә.Каринның “Тавык” шигырен уку | Шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итәргә; фланелеграфта шигырь эчтәлегенә туры килгән рәсемнәр яки уенчыклар күрсәтергә; тавыкны рәсемнәрдә һәм уенчыкларда танырга өйрәтергә. Тәрбияче артыннан кайбер фразаларны кабатларга өндәп, балаларның сөйләмен активлаштырырга.<br>Балаларның игътибарын, кабул итүләрен, сорауларга җавап бирү осталыкларын үстерергә.<br>Әбиләргә карата ихтирам, игътибар, ярату хисләре тәрбияләү. |
| | | Э.Шәрифуллинаның “Иң матур әни” шигырен уку. | Шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итәргә. Тәрбияче артыннан кайбер фразаларны кабатларга өндәп, балаларның сөйләмен активлаштырырга.<br>Балаларның игътибарын, кабул итүләрен, сорауларга җавап бирү осталыкларын үстерергә.<br>Әниләргә карата ихтирам, игътибар, ярату хисләре тәрбияләү. |
| **09.03.-20.03.** | **Халык** | “Камыр | Балаларны “Камыр малай” әкияте белән таныштырырга, әкиятнең эчтәлеген |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **иҗаты** | малай” әкиятен уку (рус халык әкияте). | аңларга ярдәм итәргә. Шар әвәләү (камыр кисәген түгәрәкләү хәрәкәтләре ясап кулларда тәгәрәтү) күнекмәсен ныгытырга.<br>Сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Әкиятләрне тыңлау, аңа карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | “Камыр малай” әкиятен кабатлау. | Әкиятне тәрбияче белән бергә сөйләргә өйрәтергә, аерым фразалар әйтү хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга.<br>Балаларның игътибарын, кабул итүен үстерергә.<br>Әкият геройларына карата кызыксынучанлык тәрбияләргә. |
| | | “Теремкәй” рус халык әкиятен уку. | Балаларны яңа әсәр белән таныштырырга; әкиятне игътибар белән тыңларга өйрәтергә.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>Халык иҗатына кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | “Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерү. | Әкият белән таныштыруны дәвам итәргә. Аваз ияртемнәрен ачык кабатларга өйрәтергә.<br>Сәхнәләштерүгә кызыксыну уятырга; уен барышында фразаларны дөрес әйтү осталыгын үстерергә.<br>Халык әкиятләренә кызыксыну тәрбияләргә. |
| **01.04.-30.04.** | **Яз** | Ш.Галиевнең “Яз” шигырен уку | Балаларның шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешергә, шигырь ярдәмендә яз турындагы белемнәрен киңәйтергә, [т] авазын, “тып” аваз ияртемен ачык итеп әйтүдә күнектерергә; сүзлек запасын киңәйтергә һәм активлаштырырга.<br>Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, кызыксынучанлыгын үстерергә.<br>Язгы табигать күренешләренә соклану хисе тәрбияләргә. |
| | | “Тор-тор, тургай” (баланы уятканда) такмагын уку. | Такмакның эчтәлеге белән таныштырырга; [т] авазын ачык итеп әйтүдә күнектерергә.<br>Аваз ияртемнәрен әйтү хисабына балаларның сүзлекләрен үстерергә.<br>Фольклор әсәрләренә кызыксыну тәрбияләргә кошларга карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | “Тук, тук, тукран...” эндәшен уку. | Шигъри текстны тыңлый белү осталыгы формалаштырырга, кошлар (тукран белән) таныштыруны дәвам иттерергә, аваз ияртемнәрен ачык кабатларга, [т], [к] авазлары әйтелешен кабатларга.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>Кошларга карата сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | “Кояш, чык,чык...” эндәшен уку. | Балаларга эндәшнең эчтәлеген аңларга, сюжетның эзлеклелеген истә калдырырга ярдәм итәргә.<br>Тыңлый белү сәләтен, эмоциональ сферасын үстерергә.<br>Күмәк эшкә кызыксыну тәрбияләргә . |
| | | Р.Батулланың “Нурбәк” | Әкиятне игътибар белән аңлап тыңларга өйрәтүне дәвам итәргә; [а], [у], [ә] сузык авазларын һәм аваз ияртемнәрен ачык итеп әйтүдә күнектерергә; әкият |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | әкиятен уку. | персонажларын уенчыкларда танырга һәм атарга өйрәтергә.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>Әкият геройларына карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | К.Д.Ушинскийнын “Казлар” хикәясен уку. | Казларны һәм үрдәкләрне аера белергә өйрәтергә, матур әдәбият әсәре - хикәяне күрсәтмәлелек кулланмыйча тыңлый белүләренә ирешергә; аваз ияртемнәрен аермачык әйтүдә, күплек һәм берлек сандагы исемнәрне аера белүдә һәм дөрес куллануда күнектерергә.<br>Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен, тәрбиягенең күрсәтмәләрен үти алу осталыкларын үстерергә.<br>Йорт кошларына карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| **01.05.-31.05.** | **Җәй** | Ә.Кариның “Чебиләр” шигырен уку**.** | Күрсәтмәлелек кулланмыйча шигъри әсәрне тыңларга өйрәтергә; кайбер фразаларны тәрбияче артыннан кабатларга өндәргә, [ч] авазын, аваз ияртемнәрен дөрес әйтүдә күнектерергә.<br>Эмоциональ сфераны үстерергә.<br>Йорт кошларына карата кайгыртучанлык тәрбияләргә. |
| | | С.Сөләймpraneның “Кызыл әтәч” шигырен уку. | Шигъри әсәрне тыңларга өйрәтергә; гади сорауларга җавап бирү теләге уятырга, “кикри-күк” аваз ияртемен кабатлауда күнектерергә.<br>Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен, тәрбиягенең күрсәтмәләрен үти алу осталыкларын, эмоциональ сферасын үстерергә.<br>Йорт кошларына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләргә. |
| | | Д. Гарифуллинның “Мыраубикә” шигырен уку. | Шигырь ярдәмендә песи белән таныштыруны дәвам итәргә, песи турындагы белемнәрен ныгытырга һәм киңәйтергә, “мыр-мыр”, “гыр-гыр” аваз ияртемнәрен ачык итеп кабатлауда күнектерергә.<br>Сорауларга җавап бирү теләге үстерергә.<br>Песиләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләргә. |

**Беренче кече яшьтәгеләр төркемендә сөйләм телен үзләштерү дәрәҗәләренә диагностика**
**Диагностик биремнәр (5-14 ноябрь)**

**1. Баланың сүзлек запасы**

1). Дидактик уен “Бу нәрсә?”

Материал: уенчыклар, җиләк-җимеш, яшелчәләр сурәтләнгән предметлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага уенчыклар (машина, курчак, туп) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы уенчыкларны атарга куша: - Бу нәрсә? Аннары предметларның өлешләрен күрсәтергә тәкъдим итә. Мәсәлән: машинаның кабинасын күрсәт. – Кузовын күрсәт. - Тәгәрмәчләрен күрсәт.

Тәрбияче балага җиләк-җимешләр (алма, груша, слива) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы җиләк-җимешләрне атарга куша: - Бу нәрсә? Балаларга җиләк-җимешләрнең төсләрен (кызыл, яшел, сары) атарга тәкъдим итәләр.

Тәрбияче балага яшелчәләр (кишер, кыяр, помидор) сүрәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы яшелчәләрне: - Бу нәрсә? Балаларга яшелчәләрнең төсләрен (кызыл, яшел, кызыл) атарга тәкъдим итәләр.

2). Дидактик күнегү “Син кем?”

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче баланы үзе янына чакыра, аңа сораулар бирә: - Синең исемең ничек? - Ә минем исемем ничек? - Мин кыз, ә син кем? – Башыңны күрсәт әле. – Кая синең борының (күзләрең, колакларың, кулларың, аякларың)?

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – предметларның исемен атаганда, төсләрен билгеләгәндә хаталар җибәрә. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый.

**2 балл** – предметларның исемен дөрес атый, төсләрен билгеләгәндә хаталар җибәрә. Тәрбияченең сорауларына өстәмә сораулар ярдәмендә генә җавап бирә.

**3 балл** – предметларның исемен дөрес атый, төсләрне дөрес билгели. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

1). Дидактик уен “Кем нәрсә эшли?”

Материал: табибә, шофёр, сатучы сурәтләнгән сюжетлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага табибә төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Табибә). Ул нәрсә эшли?

(Тыңлый). Ул кемне дәвалый? (Малайны дәвалый).

Тәрбияче балага шофёр төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Шофёр). Шофёр кайда утыра? (Кабинада утыра). Ул нәрсә эшли? (Машина йөртә).

Тәрбияче балага сатучы төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Сатучы). Сатучы кайда эшли? (Кибеттә (магазинда). Ул нәрсә эшли? (Ул әйбер сата).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала биремнәрне үти алмый. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә бала хаталар ясый.

**2 балл** – бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбияченең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

**3 балл** – бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбияченең сорауларына җавап биргәндә исем белән фигыльне, алмашлык белән фигыльне яраклаштыра ала. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

1). Дидактик уен “Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?”

Материал: песи, эт, әтәч, сыер, күгәрчен, чыпчык сурәтләнгән картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага песи (эт, әтәч, сыер, күгәрчен, чыпчык) төшерелгән картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: - Бу нәрсә? (Эт). Эт ничек өрә? (Һау-һау). - Бу нәрсә? (Песи). Песи ничек кычкыра? (Мияу-мияу). - Бу нәрсә? (Әтәч). Әтәч ничек кычкыра? (Кикрикүк). - Бу нәрсә? (Сыер). Сыер ничек мөгри? (Му-у). - Бу нәрсә? (Күгәрчен). Күгәрчен ничек гөрли? (Гөр-гөр). - Бу нәрсә? (Чыпчык). Чыпчык ничек чыркылдый? (Чырык-чырык).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала 1-2 биремне генә үти ала.

**2 балл** – бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый.

**3 балл** – бала биремнәрне теләп башкара. Аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

1). Сюжетлы картина буенча әңгәмә

Материал: уйнаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы картинка.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

- Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер картинка ясаган. – Бу картинкада кем ясалган? – Балалар нәрсә эшлиләр? - Картинка сиңа ошыймы?

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә.

**2 балл** – бала җавап биргәндә 2-3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә.

**3 балл** – бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үзенең

инициативасы яки тәрбияченең үтенече буенча картинада сурәтләнгәнне сөйли ала.

**Югары дәрәҗә** - 10-12 балл.
**Уртача дәрәҗә** - 6-9 балл.
**Түбән дәрәҗә** - 3-5 балл.

## Диагностик биремнәр

**1. Баланың сүзлек запасы**

1). Дидактик уен “Бу нәрсә?”

Материал: савыт-саба, йорт җиһазлары, йорт хайваннары, кыргый хайваннар, киемнәр сурәтләнгән предметлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага савыт саба (тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, табак) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Савыт-саба).

Тәрбияче балага йорт җиһазлары (карават, өстәл, урындык, шкаф) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт җиһазлары).

Тәрбияче балага йорт хайваннары (эт, песи, сыер, кәҗә) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт хайваннары).

Тәрбияче балага кыргый хайваннар (куян, төлке, аю) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы хайваннарны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Кыргый хайваннар).

Тәрбияче балага киемнәр (күлмәк, куртка, башлык) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Киемнәр).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – предметларның исемен атаганда авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана алмый.
**2 балл** – предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә хаталар җибәрә.
**3 балл** – предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне дөрес билгели.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

1). Дидактик уен “Кем нәрсә эшли?”

Материал: китап укучы әни, өрә торган эт, уйный торган малай, рәсем ясаучы кыз сурәтләнгән сюжетлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага китап укучы әни төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Әни). Әни нәрсә эшли? (Укый). Әни нәрсә укый? (Әни китап укый).

Тәрбияче балага өрә торган эт төшерелгән сюжетлы  картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу нәрсә? (Эт). Эт нәрсә эшли?  (Эт өрә). Ул ничек өрә? (Эт һау-һау дип өрә).

Тәрбияче балага уйный торган малай төшерелгән сюжетлы  картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Малай). Малайның исеме ничек? (Бала малайга исем биреп карый). Малай нәрсә эшли? (Малай уйный). Ул нәрсә белән уйный?  (Ул машина белән уйный).

Тәрбияче балага рәсем ясаучы кыз төшерелгән сюжетлы  картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Кыз). Кызның исеме ничек? (Бала кызга исем биреп карый). Кыз нәрсә эшли? (Кыз рәсем ясый). Ул нәрсә белән рәсем ясый?  (Ул карандаш белән рәсем ясый). Кыз нәрсә рәсеме ясый? (Кыз кояш рәсеме ясый).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала биремнәрне үти алмый. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә бала хаталар ясый.

**2 балл** – бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбияченең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

**3 балл** – бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбияченең сорауларына җавап биргәндә җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбияченең сорауларына теләп,  ышанычлы итеп җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

1). Дидактик  уен “Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?”

Материал: ат, кәҗә, тавык, каз, карга сурәтләнгән картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага ат (кәҗә, тавык, каз, карга) төшерелгән картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: - Бу нәрсә? (Ат). Ат ничек кешни? (Их-ха-ха). - Бу нәрсә? (Кәҗә). Кәҗә ничек кычкыра? (Ме-е-е). - Бу нәрсә? (Тавык). Тавык ничек кыткылдый? (Кыт-кыт). - Бу нәрсә? (Каз). Каз ничек каңгылдый? (Ка-ка-ка). - Бу нәрсә? (Карга). Карга ничек каркылдый ? (Кар-кар).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала 1-2 биремне  генә үти ала.

**2 балл** – бала  биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый.

**3 балл** – бала биремнәрне  теләп башкара. Аваз иялтемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

1). Сюжетлы картина буенча әңгәмә

Материал: кар бабай ясаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы картинка.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

- Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер картинка ясаган. – Бу картинкада кем ясалган? – Балалар нәрсә эшлиләр? - Картинка сиңа ошыймы?

2). “Камыр малай” әкиятен сәхнәләштерү.

Тәрбияче өстәл театры фигуралары куллана, балаларга сәхнәләштерүдә катнашырга тәкъдим ясый.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә. Әкиятне сәхнәләштерүдә авырлыклар кичерә. Тәрбияче артыннан аерым сүзләрне генә кабатлый.

Тәрбияче: - Балалар, камыр малайны пешергәннәр әби белән

Бала: Бабай.

Тәрбияче: - Камыр малайны тәрәзә төбенә

Бала: Куйганнар.

Тәрбияче: Камыр-курчак кипкәч, тәрәзәдән

Бала: Сикереп төшә.

Тәрбияче: Камыр малай йөгереп китә, йөгерә-йөгерә урманга

Бала: Җитә.

**2 балл** – бала җавап биргәндә 2-3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә. Тәрбияче ярдәм иткәндә таныш әкиятне сәхнәләштерүдә катнаша.

Тәрбияче: - Балалар, камыр малайны пешергәннәр

Бала: әби белән бабай.

Тәрбияче: - Камыр малайны

Бала: Тәрәзә төбенә куйганнар.

Тәрбияче: Камыр-курчак кипкәч,

Бала: Тәрәзәдән сикереп төшә.

Тәрбияче: Камыр малай йөгереп китә, йөгерә-йөгерә

Бала: Урманга җитә.

**3 балл** – бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үзенең инициативасы яки тәрбияченең үтенече буенча картинада сурәтләнгәнне сөйли ала. Әкиятнең эчтәлеген сөйләгәндә эзлеклелекне саклап сәхнәләштерүдә теләп катнаша.

**Югары дәрәҗә** - 10-12 балл.

**Уртача дәрәҗә** - 6-9 балл.

**Түбән дәрәҗә** - 3-5 балл.

**“Туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү” буенча баланың персональ картасы**

| Баланың исеме фамилиясе | Баланың сүзлек запасы | Сөйләмнең грамматик ягы | Сөйләмнең аваз культурасы | Бәйләнешле сөйләм | Гомуми үсеш дәрәҗәсе | Индивидуаль эш өчен тәкъдимнәр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

**Аңлатма язуы.**

**“Туган телдә сөйләшәбез” укыту –методик комплекты** Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (23.11. 2009)655 нче номерлы боерык нигезендә расланган “Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына федераль дәүләт таләпләре” (алга таба ФДТ.-авт.),Татарстан республикасының 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтүне, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру юнәлешен тормышка ашыру максатын күздә тотып төзелде. Ул түбәндәге бурычларны билгели:

- Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;
- Тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;
- Бәйләнешле сөйләм үстерү;
- Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау(тоемлау) сәләте булдыру.

ФДТ дә билгеләнгән “Танып белү - сөйләм үсеше юнәлешенә нигезләнеп,
комплексłы - тематик план төзелде. Ул зурлар төркемендә 36 проектны, мәктәпкә әзерлек төркемендә 31 проектны һәм шул проектлар буенча төзелгән, зурлар төркемендә 98, мәктәпкә әзерлек төркемендә 100 эшчәнлек конспектларын үз эченә ала.

“Минем бакчам”, “Мин яратам сине, Татарстан”, “Саулык -зур байлык”, “Исеменә күрә-җисеме”, “Кунак булсаң-тыйнак бул”, “Исәнме мәктәп”, “Кояш системасы”, “Дуслык белән көчле без”, “Китап кайдан килә” һәм башка күп проектлар балалар һәм өлкәннәр тормышын чагылдыра, ана телен камил белергә, аның нечкәлекләренә төшенергә ярдәм итә, башка милләт халыклары белән дустанә мөнәсәбәттә яшәргә өйрәтә, экологик тәрбия күнекмәләре бирә, балаларда әхлакый сыйфатлар формалаштыра.

Бу укыту-методик комплектында ФДТ күрсәткән өч белем бирү өлкәсе карала:

**-“Танып белү ” белем бирү** өлкәсе балаларның туган як табигате, өлкәннәр хезмәте, ел фасыллары турындагы

белемнәрен тирәнәйтүне, экологик бәйләнешләрне күрә белү мөмкинлекләрен үстерүне  максат итеп куя. Шушы максатларны тормышка ашыруга ярдәм итүче  зурлар төркемендә 31 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек төркемендә  33 эшчәнлек  каралган. Балалар белән эшчәнлек  сәяхәт, күзәтү, тәҗрибәләр уздыру, төрле уеннар формасында уздырыла.

- **“Аралашу” белем бирү** өлкәсе  туган телнең нечкәлекләрен, тирәнлеген өйрәнү, сүзнең мәгънәсенә төшенү, логик фикерләү сәләтен үстерү, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну, аваз культурасы, бәйләнешле һәм кара- каршы сөйләшә белү (диалогик сөйләм) күнекмәләрен камилләштерү, сәнгатьле сөйләмне үстерү бурычларын гамәлгә ашыра. Бу белем бирү  өлкәсенә туры килгән, зурлар төркемендә 35 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек төркемендә 36 эшчәнлек тәкъдим ителә. Авазларны кабатлау, калын һәм нечкә авазларның дифференцациясе һәр эшчәнлеккә өлеш итеп кертелде. Бу өлкәдәге эшчәнлек әңгәмә, үстерелешле диалог(балалар сорау бирә, сорауларга җавап кайтара), сәхнәләштерү, өстәл театры карау, рәсемнәр карау, алар буенча хикәя төзү, уен-викториналар; тасвирлау, үз тәҗрибәсеннән чыгып  хикәя төзү, хикәяне дәвам итеп сөйләү кебек эш формаларын күздә тота.

- **“Матур әдәбият”белем бирү** өлкәсе  балаларыбызны мәрхәмәтле, әдәпле, инсафлы булырга өйрәтүче, рухи сафлыкка, хезмәт сөючәнлеккә, ярдәмчеллеккә өндәүче,  яшь үзенчәлекләрен искә алып сайланган шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр белән таныштыруны,  әдәби телдә сөйләшергә өйрәтүне максат итеп куя.  Бу белем бирү өлкәсе зурлар төркемендә  32 эшчәнлекне, мәктәпкә әзерлек төркемендә 31 эшчәнлекне  үз эченә ала. Эшчәнлек матур әдәбият әсәрләрен уку, эчтәлеген сөйләү, ятлау кебек эш формаларын кулланып оештырыла.  .

Укыту-методик комплектыФДТ дә күрсәтелгән 10 белем бирү өлкәсе: (“Сәламәтлек”, “Физик культура”, Социальләштерү”, “Хезмәт”, “Куркынычсызлык”, “Танып – белү”, “Аралашу”, “Матур әдәбият уку”, “Иҗат”, “Музыка”) буенча куелган бурычларны күздә тотып эшләндеҺәм алар турыдан-туры бердәм белем бирү эшчәнлеге  стуктурасында интегральләштереп  бирелде.

Укыту-методик комплектында тупланган материал балалар бакчасы педагогларына  балаларның сөйләмен үстерү,тирә - юнь, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында гына түгел рәсем ясау, әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү, эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура  эшчәнлекләрендә, иртән балаларны  кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә иҗади якын килеп кулланылыр һәм ныгытылыр дип өметләнәбез.

“Туган телдә сөйләшәбез” - балаларга телебезнең матурлыгын, байлыгын  аңларга, аны тоемларга, туган телебезгә карата ярату хисләре,  әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт  тәрбияләргә, үзләрендә күркәм  сыйфатлар булдырырга ярдәм итәр дип ышанасы килә.

Шушы җирдән, шушы туфрактан без.
Китә калсак үзгә бер якка,
Өянкеләр җырлап, таллар елап,
Сандугачлар моңы озата. – дип шагыйрә К.Булатованың  шигырен
укыганда, балаларга  туган җир, туган туфрак, туган телнең изгелеген, өянкеләрнең кайчан җырлаганын, талларның

ничек итеп итеп елаганын, сандугачларның моңы ничек итеп күңелне кузгатканынаңлата алсак, без үз максатыбызга ирешкән булырбыз.

**Тәрбиячегә ярдәмлек йөзеннән сөйләм үстерү методикасы бирелә.**

**Матур әдәбият әсәрләрен уку методикасы:**

1Әдәби әсәрне сәнгатьле итеп уку.
2Әдәби әсәрне максат куеп уку.
3Әдәби әсәр эчтәлеге буенча әңгәмә уздыру.
4 Әдәби әсәрне кабатлап уку.

**Матур әдәбият әсәрләренең эчтәлеген сөйләү методикасы:**

1Әдәби әсәрне сәнгатьле итеп уку.
2 Аңлашылмаган сүзләрне аңлату.
3Әдәби әсәрне максат куеп уку.
4 Эчтәлеге буенча әңгәмә уздыру.
5Әдәби әсәрне кабатлап уку.
6 Балалар тарафыннан әсәрнең эчтәлеген сөйләү.(5-6 бала)

**Шигырь ятлау методикасы.**

1Шигырьне сәнгатьле итеп уку.
2Шигырьне максат куеп уку.
3Шигырь эчтәлеге буенча әңгәмә.
4 Шигырьне кабатлап уку.
5 Балалар тарафыннан шигырьне яттан сөйләү.(5-6 бала)

**Тасвирлау хикәяләре төзү планы:**

1Бу нәрсә?(Кем?)
2 Нинди өлешләрдән тора?
3Нәрсәдән ясалган? (нинди материал)
4Ни өчен кирәк?

**Рәсем буенча хикәя төзеп сөйләү .**( Мурашковска И.Н. методикасы **)**

**1 адым-**“бүл.” (Рәсемдә кем нәрсә күрә, һәрбер бала аерым –аерым әйтә, тәрбияче схематик рәвештә балалар күргән һәм әйткән рәсемнәрне түгәрәккә алып тактага ясый)

**2 адым** – “әйдә.” (Балаларга эчтәлеге белән туры килгән ике рәсемне кушарга тәкъдим ителә һәм ни өчен дигән сорауга тулы җөмлә белән җавап бирүләре сорала.)

**3 адым** – “нинди тавышлар ишетәсең.” ( Уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү)

**4 адым** – “нинди исләр тоясың.” ( Уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү)

**5адым** –“рәсемдәге әйберләрнең сыйфатларын әйтү.” (Уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү.)
**6 адым –** Хикәя төзү**. (**Биш адымны берләштерү.)

**Комплекслы - тематик план.**
**Зурлар төркеме.**

| Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | эшчәнлек саны |
|---|---|---|
| 1.Минем бакчам. | Балалар бакчасы буйлап сәяхәт.<br>Рәсем карау һәм хикәя төзү. -“Балалар бакчасында.”<br>Шигырь ятлау -М .Фәйзуллина. “Өлкән группага күчкәч.” | 1<br>1<br>1 |
| 2.Мин яратам сине, Татарстан. | Әңгәмә – “Туган ил кайдан башлана?”<br>“ Башкалабыз- Казан.”<br>Шигырь уку- Р.Рәкыйпов. “Мин яратам сине, Татарстан.” | 1<br>1<br>1 |
| 3.Яхшы сүз - җан азыгы. | Өстәл театры - “Өч кыз” татар халык әкияте.<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү.-Ә.Бикчәнтәева. “Тәмле сүз.” | 1<br>1 |
| 4.Абдулла Алиш иҗаты. | “А. Алиш- балалар язучысы.”<br>Хикәя уку. -А.Алиш.“Каз белән аккош.” | 1<br>1 |
| 5. Хуш киләсең, ямьле көз! | Бакча тирәли сәяхәт- “Җәйләр үтте, көзләр җитте.”<br>Рәсем буенча хикәя төзү. - “Көзге табигать.”<br>Шигырь ятлау -Х.Халиков. “Көз.” | 1<br>1<br>1 |
| 6. Көз күчтәнәчләре. | Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт- “Көзге могҗиза.”<br>Сәхнәләштерү -В.Хәйруллина. “Яшелчәләр бәхәсе.”<br>Шигырь ятлау- Х.Гарданов. “Түтәлләрдә үсте яшелчә.” | 1<br>1<br>1 |
| 7. Икмәк – яшәү терәге. | “Игенче хезмәте белән танышу.”<br>Әңгәмә -“Икмәк –тормышның нигезе.”<br>Әкият уку -“Икмәк”-төрекмән халык әкияте. | 1<br>1<br>1 |
| 8. Минем гаиләм , өем, йорт җиһазлары | Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү. - “Безнең гаилә.”<br>“Әби-бабайларны хөрмәтлик.”<br>Шигырь ятлау - Ә.Бикчәнтәева. “Дәү әнием.”<br>“Һәркемнең үз йорты бар.”<br>Әңгәмә- “Йорт җиһазлары.”<br>Шигырь уку- Ә.Ерикәй. “Әти йорт төзи.” | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| 9. Табын янында. | Савыт-саба кибетенә сәяхәт.<br>Чагыштырма хикәя төзү- “Чәйнек белән самавыр.”<br>Әңгәмә.- “Мин кунак яратам.”<br>Хикәя сөйләү.- “Тәлинкәнең төбе нинди.” | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 10. Киемнәр дә безне бизиләр. | Кием – салым кибетенә сәяхәт.<br>Әңгәмә.- “Милли киемнәр.” | 1<br>1 |
| 11. Саулык –зур байлык. | “Су, һава һәм кояш-безнең белән гел юлдаш!”<br>Сәхнәләштерү.- “А.Алиш. “Куян кызы” әкияте.<br>Шигырь ятлау. -Ә.Ерикәй. “Чисталык сөябез.” | 1<br>1<br>1 |
| 12. Исеменә күрә-җисеме | Әңгәмә. -“Исемең матур, кемнәр куйган.”<br>“Без дә хокуклы.” | 1<br>1 |
| 13. Салкын кыш.Кышкы уеннар. | Әңгәмә - “Без суыктан курыкмыйбыз.”<br>Тәҗрибә – “Бер хәлнең икенче хәлгә күчүе.”<br>Рәсем буенча хикәя төзү. -“Кышкы уеннар.”<br>Хикәя уку- К.Ушинский. “Кыш әбинең шуклыгы.” | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 14. Бездә кышлаучы кошлар. | Балалар бакчасы тирәли экскурсия -“Җимнәр сибәм кошларга.”<br>Рәсем карау- “Кошлар килгән җимлеккә.”<br>Шигырь ятлау.-Д.Гарифуллин. “Песнәк.” яки<br>Шигырь уку.- Г.Лотфи.”Балалар ярдәм итә.” | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 15. Кыргый хайваннар. | Төркемдә уен оештыру.- “Зоопаркка сәяхәт.”<br>Рәсем буенча хикәя төзү. -“Куяннар.”<br>Әкият уку,сәхнәләштерү.- “Төлке белән бүре.” Татар халык әкияте.<br>Әкият уку. - “Бүре аларны нигә ашаган.” Болгар халык әкияте. | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 16. Йорт хайваннары һәм кошлары. | Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү.- “Ишегалдында.”<br>Рәсем карау. -“Песи һәм песи балалары.”<br>Хикәянең эчтәлеген дәвам итеп сөйләү.-Г.Мөхәммәтшин.”Ак песи.” | 1<br>1<br>1 |
| 17. Транспорт. | “Җир өсте, һава, су транспорты.”<br>Чагыштырып тасвирлау хикәясе төзү. - “Йөк машинасы һәм җиңел машина.” | 1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Хикәя уку. - И. Дәүләтшин. “Алпамыш шәһәргә килде.” | 1 |
| 18. Юл йөрү кагыйдәләре. | “Машина йөртүче һәм җәяүлене кисәтүче куркынычсызлык билгеләре.”<br>Әңгәмә - “Велосипед- минем дустым.”<br>Шигырь ятлау. - Ш.Галиев. “Светофорның өч күзе.” | 1<br><br>1<br>1 |
| 19. Хезмәт төбе – хәзинә. | Төзелеш булган җиргә сәяхәт яки рәсем карау. “Хезмәткә хөрмәт.”<br>Әңгәмә. - “Кем булырга.”<br>Хикәя уку.- К.Ушинский. “Иртәнге нурлар.” | 1<br>1<br>1 |
| 20. Кунак булсаң-тыйнак бул! | Әңгәмә.- “Сүз эчендә энҗе бар.”<br>Шигырь уку.- В.Хәйруллина. “Табын кагыйдәләре.” | 1<br>1 |
| 21.Рәсәй –зур дәүләт | “Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел...”<br>Әңгәмә. – “Теле барның-иле бар.” | 1<br>1 |
| 22. Батырлыкта –матурлык. | “Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар.”<br>Шигырь уку. - Җ.Дәрзаман. “Солдат булдым.” | 1<br>1 |
| 23. Заманча әкиятләр. | “Винни - пух кунакка бара”-минем яраткан мультфильмым.” | 1 |
| 24. Кояш гомере телим мин, әнием сиңа! | Әңгәмә.- “Әни кирәк.”<br>Шигырь ятлау.-Н.Гайсин. “Әни гөлләре”. | 1<br>1 |
| 25. Без язны яратабыз. | Балалар бакчасы тирәли максатчыл күзәтү.<br>Рәсем буенча хикәя төзү.- “Яз.”<br>Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау.<br>Шигырь ятлау.- М.Мазунов. “Яз килә.”<br>Тәҗрибә үткәрү.- “Суган утырту” | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 26. Безнең канатлы дусларыбыз. | Терәк сораулар буенча рәсемгә карап чагыштырма хикәя төзү. “Сыерчык белән карга, яз килүгә шатлана.”<br>Уен - викторина. “Кошлар - безнең дусларыбыз!”<br>Шигырь уку- Г.Тукай. “Карлыгач.” | 1<br><br>1<br>1 |
| 27. Хәрәкәттә-бәрәкәт. | “Минем яраткан спорт төре.”<br>Шигырь уку. - В.Хайруллина. “Туплар.” | 1<br>1 |
| 28. Су яшәү чыганагы. | Әңгәмә. - “Яңгыркаем яу, яу!” | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Тәҗрибә.- “Суның үзенчәлекләре.” | 1 |
| 29. Уттан саклан! | Әңгәмә.- “Янгын куркынычсызлыгы!”<br>Шигырь уку.- Г.Гыйльманов. “Ярый әле.” | 1<br>1 |
| 30. Бүлмә гөлләре. | “Хуш исле нәфис гөлләр. “<br>Тәҗрибә. - “Кояш, су һәм һаваның үсемлекләр өчен әһәмияте.” | 1<br>1 |
| 31. Галәм киңлекләре | Уен “Планетарийга сәяхәт.” | 1 |
| 32. Г. Тукай иҗаты. | “Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты.”<br>Сәхнәләштерү.-Г.Тукай. “Бала белән күбәләк.”<br>Шигырь ятлау.- З.Туфайлова. “Тукай абый.” | 1<br>1<br>1 |
| 33 Урман- җиребезнең матурлыгы, байлыгы. | Урман почмагына экскурсия.<br>“Камканы күзәтү.”<br>“Кызыл китап нәрсә ул?”<br>Әкият эчтәлеген сөйләү.- Ф.Зариф. “Татлы җәй.” | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 34. Җиңү алып килде май. | Сугыш ветераннары белән очрашу. “Бөек җиңү.”<br>Шигырь уку.- Э. Шарифуллина. “Минем бабай.” | 1<br>1 |
| 35. Чәчәкләр – тормыш яме. | Уен-викторина.- “Чәчәкләр - тормыш яме.” | 1 |
| 36. Алдакчы, саран булма. | Хикәя уку.-Н.Фәттах. “Велосипедлы Мөнир.” | 1 |
| 37 | Хуш киләсең, ямьле җәй! | |

**Комплекслы - тематик план.**

**Мәктәпкә әзерлек төркеме.**

| Проект темалары. | Эшчәнлек төрләре. | эшчәнлек саны |
|---|---|---|
| 1. Белем бәйрәме. | Мәктәпкә экскурсия.- “Исәнме, мәктәп!”<br>Әңгәмә. -“Белем бәйрәме.”<br>Хикәя уку.- М .Хәсәнов. “Сара мәктәпкә бара.” | 1<br>1<br>1 |
| 2. Аралашу әдәбе. | Әңгәмә. -“Тәмле сүз-җан азыгы.”<br>Хикәя эчтәлеген сөйләү.- В. Осеева. “Тылсымлы сүз.” | 1<br>1 |
| 3. Туган ягым –яшел бишек. | “Минем туган җирем.”<br>Әңгәмә. -“Минем гүзәл халкым.” | 1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| | “Туган ягым язучылары.”<br>“Татарстан буйлап сәяхәт.”<br>Әңгәмә.- “Чал тарихлы Казаным.”<br>Шигырь уку.- Ә. Синегулов. “Татарстан җирләре.” | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 4.Абдулла Алиш иҗаты. | А. Алиш иҗаты белән танышу.<br>Әкиятнең эчтәлеген сөйләү.- “Сертотмас үрдәк.” | 1<br>1 |
| 5. Алтын көз! | Урман почмагына экскурсия.<br>Рәсем буенча хикәя төзү.- “Алтын көз.”<br>Шигырь ятлау. - М. Җәлил. “Көз житте.” | 1<br>1<br>1 |
| 6. Яшелчә, җиләк-җимеш. | “Бакчада көзге эшләр.”<br>Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү.- “Мин уңыш җыйдым.”<br>Шигырь уку. -Х. Халиков. “Дәү әнием-бакчачы.”<br>“Көз күчтәнәчләре.”<br>Рәсем буенча хикәя төзү.- “Көзге эшләр.”<br>Шигырь уку.- Н. Мадьяров. “Балан.” | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 7. Икмәк – яшәү терәге. | “Игенченең тырышлыгы кырларыннан күренә.”<br>Картина карау.- И. Шишкин. “Арыш басуы.”<br>Шигырь уку.- Р. Вәлиева. “Ашлар солтаны.” | 1<br>1<br>1 |
| 8. Гаилә һәм йорт җиһазлары. | “Минем өем, өй җиһазлары.”<br>Әңгәмә.- “Нәрсә ул электр һәм электр җиһазлары?”<br>Иҗади хикәя төзү. -“Тату гаилә.”<br>Шигырь уку. -З. Туфайлова. “Минем гаиләм.” | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 9.Ашамлыклар һәм савыт-саба. | Ашханәгә экскурсия.<br>Әңгәмә.- “Кунак чакырдык.”<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү.- С.Сәүбәнова. “Ботка нигә тәмле.” | 1<br>1<br>1 |
| 10. Милликиемнәр. | Танышу уены.- “Әбиемнең серле сандыгы.”<br>Чагыштырып хикәя төзү.- “Кием кешене бизи.”<br>Шигырь уку. -Р. Вәлиева. “Кәләпүшем, кәләпүш.” | 1<br>1<br>1 |
| 11. Кыш. Кышкы уеннар. | Паркка экскурсия. - “Килеп җитте матур кыш.” | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Әңгәмә.- “Паркта минем күргәннәрем.”<br>Шигырь ятлау.- Г. Латыйп. “Кыш килде.”<br>“Боз һәм бозлыклар.”<br>Иҗади хикәя төзү.- “Кышкы уеннар.”<br>Язма сөйләм.- “Кыш бабайга хат.” | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 12.Кыргый хайваннар. | “Кайда, ничек кышлыйлар.”<br>Рәсем буенча хикәя төзү.- “Кыш. Тиеннәр.” | 1<br>1 |
| 13. Кышлаучы кошлар. | Кошларны күзәтү. -“Безнең канатлы дусларыбыз.”<br>“Кошларга ярдәм итик.”<br>Калмык халык әкиятен  уку.-  “Күңелле чыпчык белән күңелсез карга.” | 1<br>1<br>1 |
| 14. Йорт хайваннары һәм кошлары. | “Авылда ишегалды.”<br>Картина буенча хикәя төзү.- “Йорт хайваннары. Ат белән колын.”<br>Әкиятнең эчтәлеген сөйләү.- “Үрдәк беренчелекне алган.” | 1<br>1<br>1 |
| 15.Транспорт, юл йөрү кагыйдәләре. | “Транспорт төрләре белән танышу.”<br>Әңгәмә.- “Юл йөрү кагыйдәләре кирәк безгә һәркөнне.”<br>Шигырь ятлау.- Г. Юнысова. “Светофор.” | 1<br>1<br>1 |
| 16. Һөнәрләр. | Балалар бакчасы буйлап сәяхәт. “Безне җырларга кем өйрәтә.”<br>Әңгәмә. -“Әти-әниләр һөнәре.”<br>Шигырь уку.- Э. Мөэминова. “Фокусчы.”<br>Укытучы хезмәте белән таныштыру. “Укытучы.” | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 17.Мультфильмда кунакта. | Әкиятне дәвам итеп сөйләү.- “Күчтәнәч”тә кунакта.”<br>Әңгәмә.- “Әкиятләр иленә сәяхәт.” | 1<br>1 |
| 18. Мин дөньяның бер кешесе. | Әңгәмә. -“Мин бәхетле-мин хокуклы.”<br>“Тигез хокук белән яшик бу җирдә.” | 1<br>1 |
| 19.Мин һәм минем сәламәтлегем. | Шифаханәгә (шәфкать туташы бүлмәсенә) экскурсия. “Шәфкать туташы.”<br>Фикер алышу.- “Сәламәтлек – зур байлык.”<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү.-  В. Монасыйпов “Шифалы табиблар.” | 1<br>1<br>1 |
| 20. Муса Җәлил.<br>Ил сакчылары. | “Кемнәр алар ил сакчылары.”<br>“Муса Җәлил – бөек шагыйребез”. (Сәхнәләштерү. М.Җәлил “Карак песи.”)<br>Шигырь уку.- Р. Корбан “ Җәлил турында җыр.” | 1<br>1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| 21. Халыкара телләр көне. | Фикер алышу. -“Дуслык бөек көч.”<br>Әңгәмә. - “Россия – безнең илебез.”<br>Шигырь ятлау. -Х.Халиков. “Сөйләшсәләр безнеңчә.” | 1<br>1<br>1 |
| 22. Бүлмә гөлләре. | Тәҗрибә үткәрү.- “Ни өчен орлыкларны, үсемлекләрне балчыкка утырталар.”<br>Хикәя төзү. -“Кактус белән фикус гөлен чагыштыру.”<br>Шигырь уку. Ә.Габиди. “Минем гөлләрем.” | 1<br>1<br>1 |
| 23. Ямьле яз. | Паркка экскурсия.- “Туган якка яз килде.”<br>Эчтәлекле рәсемнәр сериясе буенча хикәя төзү.-“Яз. Сыерчыклар.”<br>Шигырь уку.- Н. Мәдьяров. “Көләч яз.”<br>Күзәтү. -“Ак болытлар ага зәңгәр күктә.” | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 24.Исәнмесез, кошкайлар. | “Күчмә кошлар безгә яз алып килде.”<br>Шигырь ятлау.- Г. Юнысова. “Кара.” | 1<br>1 |
| 25. Урман. Кызыл китап. | “Нәрсә ул кызыл китап.”<br>Әңгәмә. -“Урман безнең байлыгыбыз.”<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү.- Р. Төхвәтуллин. “Шомырт нигә елый.”яки<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү. - Пришвин.”Алтын болын.” | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 26.Китап кайдан килә. | Китапханәгә экскурсия.<br>Бирелгән сүзләрдән хикәя төзү.- “Китап кибете.”<br>Шигырь уку.- Х. Халиков. “Китап докторы.” | 1<br>1<br>1 |
| 27. Космос. | “Нәрсә ул кояш системасы?”<br>Әңгәмә.- “Космонавтика көне.”<br>Шигырь уку.- Йолдыз. “Сәлам, галәм.” | 1<br>1<br>1 |
| 28. Спорт. | “Казанда Универсиада.”<br>Рәсем буенча хикәя төзү.- “Спорт мәйданчыгында.”<br>Шигырь ятлау.- Г.Юнысова. “Зарядкага бас.” | 1<br>1<br>1 |
| 29. Г. Тукай иҗаты. | Әдәби викторина.- “Мультфильмда кунакта.”<br>Сәхнәләштерү.- Г. Тукай. “Кызыклы шәкерт.”<br>Шигырь уку. - Г. Тукай. “Эш беткәч, уйнарга ярый.”<br>“Г. Тукай һәм балалар.” | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 30. 9 нчы май-Җиңү көне. | Ветераннар белән очрашу.- “Алар безгә җиңү бүләк итте.” | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Хикәянең эчтәлеген сөйләү. -Л. Кассиль. “Күңелләрдә мәңге сакланыр.” | 1 |
| 31.Хуш бакчам, исәнме, мәктәп! | “Без барабыз мәктәпкә.”<br>Сәхнәләштерү.- Г. Тукай. “Һәркем эштә.”<br>Шигырь ятлау.- Б. Рәхмәт. “Мәктәпкә.” | 1<br>1<br>1 |

**Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр.**
**(зурлар төркеме).**

| Танып белү. | Аралашу. | Матур әдәбият уку. |
|---|---|---|
| -Транспорт төрләрен кеше тормышын җиңеләйтүче, уңайлыклар тудыручы әйберләрне белү.<br>-Предметның төсе күләме, формасы, зурлыгы, авырлыгы, нинди материалдан эшләнгән булуы турында сөйли алу, аларны төркемләү.<br>-Төрле һөнәрләр (төзүчеләр, авыл эшчәннәре...) турында белү.<br>-Туган шәһәрең (авылың) , туган илең, аның башкаласы, юл йөрү кагыйдәләрен белү.<br>-Үз туганнары , үзе турында сөйли алу, өй адресын әйтү.<br>-Табигать күренешләрен күзәтеп, алар арасындагы бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара алу,  кайбер закончалыкларны белү. | -Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллану, Туры һәм кыек сөйләмнән файдалану.<br>-Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча мөстәкыйль рәвештә хикәя төзү.<br>-Әкиятләрнең ахырын тәмамлау, зур булмаган әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә интонацияләрдән дөрес файдалану.<br>-Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләр куллану.<br>-Мәгънәдәш сүзләр һәм капма-каршы сүзләр куллану.<br>-Аралашуда актив булу, теләп катнашу. | -Әсәрнең жанрын билгели алу (әкият, хикәя).<br>-Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерү, рольләргә бүлеп шигырьләрне сөйләү.<br>-Яраткан язучыларны атый белү.<br>-Укыту методик комплектында күрсәтелгән 2-3 шигырьне сөйләү, табышмак, мәкальләрне искә төшереп әйтү.<br>-Әдәби персонажның кылган гамәлләре турындагы фикерләрен башкаларга сөйләү.<br>-Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйли белү. |

**Балаларның белем дәрәҗәләре үсеше күрсәткече. (зурлар төркеме).**
**Танып белү**.

**Югары дәрәҗә**.(3 балл.) Балалар транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтүче, уңайлыклар тудыручы әйберләрне таный һәм әйтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында сөйли, аларны төркемли белә. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында белә. Юл йөрү кагыйдәләрен дөрес әйтә. Туган иле, шәһәре (авылы),Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә. Үз туганнары, үзе турында

сөйли, адресын әйтә. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны белә, алар арасындагы бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара.
**Уртача дәрәҗә.(2 балл.)**Балалар транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтүче, уңайлыклар тудыручы әйберләрне атаганда хата җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тулысынча сөйләми, исенә төшергәч, өстәп сөйли белә, төркемли ала. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматне тулысынча биреп бетерә алмый. Туган иле, шәһәре (авылы),Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә. Үз туганнары, үзе турында аз сөйли, сораулар биргәч үзлектән тулыландыра. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлатканда, үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгарганда кыенлыклар кичерә.
**Уртачадан түбән дәрәҗә.(1 балл.)** Балалар транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтүче, уңайлыклар тудыручы әйберләрне атаганда хата җибәрә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тәрбияче ярдәменнән башка сөйли белми,   төркемли алмый. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүмате юк. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында әйтә белми. Үз туганнары, үзе турында тәрбияче ярдәмендә сөйли. Адресын белми. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлата, үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара алмый.

## Аралашу.

**Югары дәрәҗә. (3 балл.)**Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллана белә, туры һәм кыек сөйләмнән файдалана. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча мөстәкыйль рәвештә хикәя төзи. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә, иҗади хикәяләр төзегәндә интонацияләрдән дөрес файдалана. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләр куллана белә. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне дөрес әйтә белә.Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда теләп катнаша. үстерелешле аралашуда катнашу дәрәҗәсе камил.
**Уртача  дәрәҗә.** (2 балл.)  Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр кулланганда хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белә. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбиче ярдәмен көтә, бик үк мөстәкыйль түгел. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген тулы бирми, иҗади хикәяләр төзегәндә иҗади түгел. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләрне аз куллана.  Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне  әйткәндә хаталар җибәрә.Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда  катнаша, үстерелешле аралашуда  катнашуы камил дәрәҗәдә түгел.
**Уртачадан түбән дәрәҗә.(1 балл.)** Бала **с**өйләмдә гади җөмләләр куллана, үз тәҗрибәсеннән чыгып начар сөйли, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген план буенча сөйли белми, иҗади хикәяләренең эчтәлеге гади, интонацияләрдән файдаланмый. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләрне аз  куллана. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйтми.Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда сирәк  катнаша, үстерелешле аралашуда катнашуы юк дәрәҗәдә.

## Матур әдәбият уку.

**Югары дәрәҗә. (3 балл.)** Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя)аера ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә

бүлеп шигырьләр укуда актив катнаша, тиз истә калдырып яттан сөйли. Язучыларны таный һәм атый, әсәрләрен белә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сөйләмдә мөстәкыйль куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйләп бирә ала.

**Уртача дәрәҗә.** (2 балл.) Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя)аерганда ялгышлыклар җибәрә, ләкин тәрбияче ярдәмендә үзлектән төзәтә ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда активлык күрсәтми, ләкин катнаша. Язучыларны таный, әсәрләрен әйтүдә кыенлыклар кичерә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сирәк куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя биргәндә хаталар җибәрә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга тулы итеп сөйләми.

**Уртачадан түбән дәрәҗә.(1 балл.)** Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя)аера алмый. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда катнашырга теләге юк. Язучыларны танымый, әсәрләрен әйтә алмый. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны кулланмый. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя бирә белми. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйли белми.

**Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр.**
**(мәктәпкә әзерлек төркеме.)**

| Танып белү. | Аралашу. | Матур әдәбият уку. |
|---|---|---|
| -Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллау.<br>-Экологик бәйләнешләрне аңлата алу, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысын белү.<br>-Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүматле булу.<br>-Предметларны үзләренә генә хас билгеләре, үзнчәлекле сыйфатлары буенча аерып ала һәм төркемли белү.<br>-Үзе турында, (Ф.И.О., адрес, № телефон, әти-әнисе)сөйли белү, өлкәннәр хезмәте, аларның эшлекле сыйфатлары турында мәгълүматле булу. | -Күмәк сөйләмдә катнашу (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара, вакыйгаләр, фактлар,күренешләр турында эзлекле мәгънәле, аңлаешлы итеп сөйли.)<br>-Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап төгәл куллану.<br>-Сүзләрне контексттагы мәгънәсенә туры китереп сөйли белү күнекмәләре булу.<br>Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып иҗади хикәяләр төзи белү.<br>Тәрбияче, һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белү. | -Әсәрнең жанрын билгели алу (Әкият, хикәя, шигырь.)<br>-Китап геройларының хәленә керә белү, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирү, үз мөнәсәбәтен белдерү.<br>- Шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйләү, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә белү.<br>-Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен тану.<br>-Китаплардан яңа белемнәр алу мөмкинлеген аңлау. |

**Балаларның белем дәрәҗәләре үсеше күрсәткече.**

**(мәктәпкә әзерлек төркеме).**

**Танып белү**.

**Югары дәрәҗә. (3 балл.)**Бала сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллый. Экологик бәйләнешләрне аңлата ала, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысын беләТабигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмат бирә ала.Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйли, аларны төркемли белә.Үзе турында, (Ф.И.О., адрес, № телефон, әти-әнисе)сөйли белә, өлкәннәр хезмәте, аларның эшлекле сыйфатлары турында мәгълүмате бар.

**Уртача дәрәҗә.** (2 балл.) Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында баланың күзаллавы җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Экологик бәйләнешләрне күрүдә авырыксына, тәрбияче яки балалар ярдәмендә үзе җавап бирә.Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмате бар, дөрес итеп тәрбияче ярдәмендә аңлата. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйлгәндә хаталар җибәрә, төркемләгәндә хаталар җибәрсә үзлектән төзәтә белә .Үзе турында, (Ф.И.О., адрес, № телефон, әти-әнисе) мәгълүмате тулы түгел.

**Уртачадан түбән дәрәҗә.(1 балл.)**Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында бала күзалламый. Экологик бәйләнешләрне, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысы турында әйтә белми. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмат бирә алмый. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйли әмма аларны , төркемләми. Үзе турында, (Ф.И.О., адрес, № телефон, әти-әнисе) мәгълүмате аз.

**Аралашу.**

**Югары дәрәҗә** (3 балл.)Бала күмәк сөйләмдә актив катнаша (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара, вакыйгаләр, фактлар,күренешләр турында эзлекле мәгънәле, аңлаешлы итеп сөйли.).Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап төгәл куллана ала.Сүзләрне контексттагы мәгънәсенә туры китереп сөйли белә.Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып үзлектән иҗади хикәяләр төзи белә.Тәрбияче, һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белә. Бәйләнешле сөйләме чиста, грамматик яктан дөрес.

**Уртача дәрәҗә.** (2 балл.)Бала күмәк сөйләмдә катнаша (сорауларны аз бирә, сорауларга җавап кайтара, вакыйгаләр, фактлар,күренешләр турында эзлекле сөйләгәндә хаталар җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә).Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча кулланганда хаталар җибәрә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып иҗади хикәяләр төзегәндә хаталар җибәрә, тәрбияче ярдәмендә үзлектән төзәтә ала.Тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белә.

**Уртачадан түбән дәрәҗә.(1 балл.)**Бала күмәк сөйләмдә катнашмый (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара алмый вакыйгаләр, фактлар, күренешләр турында эзлекле сөйләгәндә хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белми).Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча кулланганда хаталар җибәрә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып үзлектән иҗади хикәяләр төземи.

**Матур әдәбият уку.**

**Югары дәрәҗә.(3 балл.)** Әсәрнең жанрын билгели ала (әкият, хикәя, шигырь). Китап геройларының хәленә керә белә, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә, үз мөнәсәбәтен белдерә. Шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйли, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә белә. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таный.Китаплардан яңа белемнәр алу мөмкинлеген аңлый.

**Уртача дәрәҗә.** (2 балл.)Әсәрнең жанрын билгеләүдә (әкият, хикәя, шигырь) хаталар җибәрә. Китап геройларының хәленә керә белә, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә, үз мөнәсәбәтен аңлата алмый. Шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сөйләгәндә сәнгатьлелек җитми.Эчтәлеге буенча сорауларга җавап биргәндә хаталар җибәрә. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таныганда, хаталар җибәрә, күп очракта үзлектән төзәтми. Китаплар белән кызыксына, мөстәкыйльлеге чамалы.

**Уртачадан түбән дәрәҗә.(1 балл.)** Бала әсәрнең жанрын (әкият, хикәя, шигырь) тәрбияче ярдәменнән башка билгели алмый. Китап геройларының хәленә керә белми, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә алмый, үз мөнәсәбәтен дөрес аңлата алмый. Шигырьләрне тиз истә калдырмый, сәхнәләштергән әсәрләрне сөйләгәндә сәнгатьлелеге, иҗадилыгы юк. Эчтәлеге буенча сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә яки бирә алмый. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таныганда күп хаталар җибәрә. Китаплар белән кызыксынмый.

## Кулланылган әдәбият.

1. Ал кирәк,гөл кирәк (методик кулланма). Р. Ягъфәров.- Казан. 1995.
2. Балачак аланы (хрестоматия). К.В.Закирова. - Казан. 2011.
3. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы. М.А.Васильева, В.В. Гербова, Т.С. Комарова. - Казан Мәскәү.2006.
4.Балалар бакчасында татарча сөйләм үстерү дәресләре (методик кулланма.) З.М. Зарипова, А.И.Касимова.- Казан 2010.
5. Бала бишеге-гомер ишеге (җыентык). Ф.Зарипова... - Яр Чаллы. 2000.
6. Белем бирү һәм тәрбия процессында милли төбәк компоненты(методик кулланма). З.М. Зарипова. - Яр Чаллы. 2000.
7. Балалар фольклоры. Н. Исәнбәт. - Казан. 1984.
8. Балалар бакчасы (хрестоматия). Ф.Ю. Юсупов.- Казан. 2003.
9. Бал бабай. З.М.Зарипова, И.М. Хәмитов. - Яр Чаллы. 2000.
10. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү (программа). К.В.Закирова...- Казан 2009.
11. Балалар бакчаларында телдән сөйләмгә өйрәтүнең фәнни методик нигезләре (монография). М.Ф.Кашапова. - Казан. 2009.
12. Гөлбакча (хрестоматия). Ф.Ю. Юсупов... - Казан. 1990.
13. Диагностика речевого развития дошкольников. (3-7 лет). О.С.Ушакова, Е.М. Струнина. - Москва. 1999.
14. Иң гүзәл тел-туган тел (методик кулланма). М.Ф.Кашапова. - Казан. 2009.

15.Иң матур сүз (хрестоматия). К.В.Закирова. - Казан. 2000.
16. Иң татлы тел-туган тел (методик кулланма). М.Ф.Кашапова. - Казан. 2004.
17. Иҗат баскычлары (методик ярдәмлек). Р.К.Шәехова, К.В.Закирова.- Казан. 2001.
18. Көч һәм рух тамырлары (хрестоматия). К.В.Закирова, Р.А.Низамов.- Казан. 1998.
19. Кәҗә-мәкәрҗә (методик кулланма). Р. Ягъфәров.- Казан. 1994.
20. Методика развития речи детей. А. М. Бородич.- Москва. 1981.
21. Материал к занятиям по развитию речи. Т.И. Подрезова.- Москва. 2006.
22. Программа по обучению детей русскому языку. З. М. Зарипова...- Набереңные Челны. 2004.
23. Развитие речи детей 5-7 лет. ). О.С.Ушакова. - Москва. 2011.
24. Раушан көзге (хрестоматия). Р.Ш.Халикова.- Казан. 1993.
25. Туган телем- бөек анам теле (методик кулланма). З.М.Зарипова. - Яр Чаллы. 2004.
26. Табигатькә сәяхәт (методик эшләнмә). Г.М. Хәкимова. - Яр Чаллы. 2007.
27. Татар халык уеннары. Р. Ягъфәров. - Казан. 2002.
28. Татар халык табышмаклары. “Идел-йорт” нәшрияте. - Яр Чаллы. 2000.
29. Театр уйнап үсәбез (ярдәмлек). А.Т.Хуҗина. - Яр Чаллы. 2009.
30. Уйный-уйный үсәбез (хрестоматия). К.В.Закирова. - Казан. 2005.
31. Уйныйк әле, балалар (методик ярдәмлек). М.Ф.Кашапова.- Казан. 2011.
32. Юлда йөрсәң, уяу бул! Ф.Л.Гыйниятуллина. - Яр Чаллы. 2008.
33. Әхлак дәресләре (дәрес эшкәртмәләре). В. С. Казыйханов.- Яр Чаллы. 1997.
34. Әхлак белеме - (хрестоматия). В. С. Казыйханов. Яр Чаллы. 2000.
35. Әткәм-әнкәмнең теле (методик кулланма). К.В.Закирова, С.М.Гаффарова.- Казан. 1997.
36. Әдәп-матур гадәт. З.М.Зарипова. - Яр Чаллы. 2009.
37. Үз илемдә, үз телемдә (методик кулланма). Ф.М.Зиннурова.- Казан. 2009.
38. Җил каян килә (җыентык). Л. Шәех.- Казан. 2008.